# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 4*
*апрель*
*2015*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ
СОВЕТЫ РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
2015

**ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60х84 1/16. Тираж 32 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2015

## Эчтәлек

## I

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

309. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ............. 26

310. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ............. 27

311. «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ............. 30

312. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ............. 31

313. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ............. 33

314. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» *Татарстан Республикасы Законы* ............. 34

315. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........................... 40

316. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 1.1[1] һәм 8.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........................................................ 41

317. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» *Татарстан Республикасы Законы* ................ 43

318. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ................ 45

319. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ................................................................. 46

320. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ................................................................. 48

321. «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» *Татарстан Республикасы Законы* .............................. 50

322. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5[1] статьясына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ............................................ 63

323. «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләрне Татарстан Республикасы территориясендә куллану срогын билгеләү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ............ 80

324. «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» *Татарстан Республикасы Законы* ......................................................... 81

## II

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

325. «Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җиденче утырышы көн тәртибе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ............................................................ 88

326. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ............................................................ 95

327. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 5[1] статьясына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 101-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .... 96

328. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 5[1] статьясына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республика-

сы законы турында (101-5 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ............ 97

329. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 76-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .................... 97

330. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (76-5 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .................... 98

331. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .... 98

332. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.4 һәм 23.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .... 99

333. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..100

334. «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 103-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..........101

335. «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» Татарстан Республикасы законы хакында (103-5 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ............102

336. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 104-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...............................102

337. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (104-5 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*.............................103

338. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 89-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*....................104

339. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (89-5 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*....................104

340. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында» 71-5 номерлы Татарстан Республикасы законы

проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 105

341. «Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2014 елдагы эше турында хисап хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 105

342. «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» 102-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 106

343. «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы законы хакында (102-5 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 107

344. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» 93-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 107

345. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» Татарстан Республикасы законы хакында (93-5 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 108

346. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 97-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 108

347. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (97-5 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 109



348. «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләрне Татарстан Республикасы территориясендә куллану срогын билгеләү турында» 99-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 110

349. «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләрне Татарстан Республикасы территориясендә куллану срогын билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (99-5 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 110

350. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 92-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ... 111

351. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (92-5 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ... 112

352. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 100-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 112

353. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 113

354. «1990 – 2014 елларда Татарстан Республикасы законнары торышы турында доклад хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*............122

355. «Татарстан Республикасы Законнары җыелмасын чыгару буенча республика комиссиясе төзү турында» 2009 елның 5 ноябрендәге 478-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................123

356. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2014 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында доклады хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................124

357. «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык, уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составына үзгәреш кертү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .................................................................125

358. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $26^3$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 714043-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларының иҗтимагый палаталары эшчәнлеген тәэмин итүне Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*............126

359. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый палаталары (советлары) эшчәнлеген тәэмин итүне җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 717570-6 номерлы федераль закон проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*..............................................127



360. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 17 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 730431-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль районнарның һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне Россия Федерациясе субъекты законы белән яңадан бүлү мөмкинлеген бирү хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*................................127

361. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 48 статьясына һәм «Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 736559-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектында эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә норматив булмаган муниципаль хокукый актларның гамәлдә булуын туктатып тору турында күрсәтмә җибәрү мөмкинлеге бирү хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*.........................128

362. «Физик затлар тарафыннан үз мөлкәте һәм банклардагы счетлары (кертемнәре) турында үзләре теләп декларация бирү хакында» 754388-6 номерлы федераль закон проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................129

363. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 733264-6 номерлы федераль закон проекты турында (депутат эшчәнлегенә бәйле чикләүләр өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................129

364. «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 727963-6 номерлы федераль закон проекты турында (автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә

дәүләт күзәтчелеге һәм муниципаль контроль тәртибен билгеләү вәкаләтләре хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*..............................130

365. «Россия Федерациясе Торак кодексының 89 статьясына үзгәреш кертү турында» 736488-6 номерлы федераль закон проекты хакында (гражданнарга, торак урыннарыннан чыгарылуга бәйле рәвештә, уңайлыклары булган башка торак урыннар бирү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...................131

366. «Транспорт куркынычсызлыгы турында» Федераль законның 1 статьясындагы 11 пунктына үзгәрешләр кертү хакында» 715839-6 номерлы федераль закон проекты турында (кече судноларны транспорт чаралары исемлегеннән төшереп калдыру хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*............131

367. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Федераль законның 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 717554-6 номерлы федераль закон проекты хакында (статьяның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү турында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......................................132

368. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 719543-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ штрафлар билгеләү һәм исәпләү кагыйдәләрен төгәлләштерү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*.......133

369. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына дәүләт милке (муниципаль милек) белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 721715-6 номерлы федераль закон проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ................................133

370. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6 бүлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 724074-6 номерлы федераль закон проекты турында (җәмәгать урыннарында хайваннарны файдаланып теләнгән өчен җаваплылык билгеләү хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...134

371. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 733457-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чарасын йөртүченең транспорт чарасына идарә итү хокукы бирүче документлары үзе белән булмаганда транспорт чарасын тоткарлауны төшереп калдыру хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...................................135

372. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиясез йә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә каралган шартларны һәм (яисә) билгеләнгән тәртиптә расланган техник проектлар таләпләрен бозып җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен җаваплылыкны арттыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 734974-6 номерлы федераль закон проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*.................................136

373. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 741119-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чаралары хуҗаларының мәҗбүри граждан җаваплылыгын иминләштерү автоматлаштырылган системасына белешмәләрне үз вакытында һәм төгәл кертмәгән өчен җаваплылык билгеләү хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*.......137

374. «Балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклап калу турында» Федераль законның 50 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 738365-6 номерлы федераль закон проекты турында (хуҗалык эшчәнлеге һәм су биологик ресурсларына һәм аларның яшәү тирәлегенә йогынты ясый торган башка эшчәнлек башкаруны җайга салу өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*.........................................137

375. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль законның 10 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 739287-6 номер-

лы федераль закон проекты турында (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләреннән тиешенчә файдалану фактын раслый торган документлар исемлеген билгеләү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*........................................138

376. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Концессион килешүләр турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 737572-6 номерлы федераль закон проекты турында (концессион килешүләр проектларын мәҗбүри рәвештә гавами тыңлауларга чыгару өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*..............................139

377. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 65 статьясына үзгәреш кертү турында» 713728-6 номерлы федераль закон проекты хакында (хезмәт шартнамәсе төзегәндә тапшырыла торган документларның исемлеген пенсия иминләштерүенең иминият таныклыгы исеме өлешендә төгәлләштерү турында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары*.....................139

378. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 51 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Краснодар крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...140

379. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 737080-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган административ җәзалар исемлеген киңәйтү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...141

380. «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 743295-6 номерлы федераль закон проекты турында (гражданнарның язма мөрәҗәгатенә карата таләпләрне киңәйтү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...141

381. «Россия Федерациясендә адвокатлык эшчәнлеге һәм адвокатура турында» Федераль законның 33 статьясына өстәмә кертү хакында» 749037-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларының адвокатлар палаталарының квалификация комиссияләрен төзү тәртибен төгәлләштерү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..............................................142

382. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның $11^2$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...143

383. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 14.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 749023-6 номерлы федераль закон проекты турында (ирекле сату законнар нигезендә тыелган яисә чикләнгән товарларны (башка әйберләрне) законсыз саткан өчен җаваплылыкны көчәйтү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ............................................143

384. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 һәм 23.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 735304-6 номерлы федераль закон проекты турында (чит ил агенты функцияләрен башкаручы коммерциягә карамаган оешмаларның эшчәнлек тәртибен бозган өчен административ җаваплылыкка тарту вакыты чыгуны төгәлләштерү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..............................................144

385. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 346.43 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 678692-6 номерлы федераль закон проекты хакында (салым салуның патент системасы кулланыла торган хуҗалык эшчәнлеге төрләре исемлегенә икмәк

һәм икмәк-күмәч ризыкларын җитештерүне кертү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................145

386. «Россия Федерациясе Салым кодексына үзгәрешләр кертү турында» 755146-6 номерлы федераль закон проекты хакында (махсус салым режимнарын камилләштерү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................145

387. «Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җиденче утырышын чакыру турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ....................................................146

388. «Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җиденче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында » *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* .................146

## III

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘЛӘРЕ

389. «А.В. Ивановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....................................................152

390. «А.Г. Нотфуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....................................................152

391. «Фәхретдинов Илдус Нуретдин улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ...............................153

392. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Һ. Галиев, Р.Г. Ногманов, Н.Н. Рыбушкин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 97-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (1 майдан алып 1 октябрьгә кадәрге чорда сезонлы (җәйге) кафеларда сыраны һәм сыра эчемлекләрен ваклап сату мөмкинлеген беркетү өлешендә) алдан карау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....................................................153

393. «1990 елдан алып 2014 елга кадәр чорда Татарстан Республикасы законнары торышы турында доклад проектын хуплау һәм алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* .....154

394. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 16 һәм 28 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 94-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (муниципаль хезмәткә бәйле тыюларны төгәлләштерү, шулай ук тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү турында гаризага өстәлеп бирелә торган документлар исемлегеннән яшәү урыны буенча теркәлүне раслый торган документны төшереп калдыру өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе*....................................155

395. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 95-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (дәүләт граждан хезмәтенең теләсә кайсы вазыйфасын биләүгә дәгъва белдергән гражданнарның үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук үз гаиләсе әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы өлешендә) алдан карау хакын-

да» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................156

396. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Т.Г. Хадиев, Р.Р. Гайзатуллин тарафыннан кертелгән «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 96-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (җир асты суларын эзләү һәм аларга бәя бирү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын чыгару өчен яисә җир асты суларын эзләү һәм аларга бәя бирү максатларында геологик өйрәнү һәм җир асты суларын чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирүне җайга салу өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ..............157

397. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Н.Н. Рыбушкин тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 3.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 98-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (административ хокук бозу составын төгәлләштерү турында) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................158

398. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләрне Татарстан Республикасы территориясендә куллану срогын билгеләү турында» 99-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................159

399. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 100-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын («Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законын яңа редакциядә бәян итү) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе*..........................160

400. «Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының $5^1$ статьясына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 101-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренең яңа төрләрен, мактаулы исемнең яңа төрен өстәү һәм Татарстан Республикасы мактаулы исемнәре турында нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе*..................................................161

401. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Казан шәһәрендә районнар чикләре турында» 102-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* .....162

402. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 103-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе*..........................163

403. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 104-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (адми-

нистратив хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләрен бүлү) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* .....164

404. «Ш.М. Касыймуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....165

405. «Р.С. Мостафинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....165

406. «А.А. Арсентьевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....166

407. «Ф.Ф. Шәйхулловны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....166

408. «Р.И. Азюковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....167

409. «Р.Ә. Ибәтуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....167

410. «И.Д. Галимҗановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....168

411. «И.Х. Йосыповны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....168

412. «С.А. Зайцеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....169

413. «С.К. Киргизовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....169

414. «Г.Ш. Крмакованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....170

415. «Ф.З. Галимованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....170

416. «Н.Н. Васильеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....171

417. «Р.Р. Нуретдиновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....171

418. «Н.М. Шалдаеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....172

419. «Р.М. Солтанованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....172

420. «В.Н. Матвееваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....173

421. «Е.М. Денисованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турын-

да» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........173

422. «И.Р. Җиһаншинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........174

423. «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыяте филиалы «Туган як» газетасы редакциясе» коллективын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........174

424. «Л.Д. Белоусованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........175

425. «В.П. Виславсякийны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........175

426. «М.Г. Рәхмәтуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........176

427. «Р.Н. Җомаголовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........176

428. «В.И. Сутягинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........177

429. «Л.Ф. Хәкимованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........177

430. «Н.А. Шадровны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........178

431. «А.Р. Яруллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........178

432. «А.Н. Чугуновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........179

433. «А.Р. Гайнетдиновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........179

434. «В.П. Прокопьевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........180

435. «Л.С. Усманованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........180

436. «Р.Ш. Җамалетдиновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........181

437. «С.В. Павлованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........181

438. «Г.Н. Шаровны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........182

439. «Г.В. Мошковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында»

*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....182

440. «Ф.Г. Гарифуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....183

441. «В.П. Буйрованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....183

442. «Л.В. Умылинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....184

443. «В.А. Фильченкованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....184

444. «Казан шәһәре Совет районының «125 нче гимназия» муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесе укучыларын һәм педагогик коллективын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....185

445. «Р.С. Сафиуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....185

446. «Б.К. Кузнецовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....186

447. «М.Ш. Исхаковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....186



448. «Б.В. Гревцовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....187

449. «Г.Г. Алимовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....187

450. «Е.В. Любушкинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....188

451. «О.Н. Бочкареваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....188

452. Р.Р. Идрисовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....189

453. «В.И. Киндаеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....189

454. «З.Г. Мирзакриеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....190

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 309. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 9 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш), «, шул исәптән сатып алу юлы белән,» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 9 апреле
№ 18-ТРЗ





### 310. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (1 өлеш); 2012, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле 14 һәм 15 пунктлар өстәргә:
«14) социаль файдаланудагы наем йортларында торак урыннар бирүгә торак законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәүгә;
15) коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүгә чикләүләрне үтәүгә.»;
б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:
«2. Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлегенә лицензия бирә.»;

2) $6^1$ статьяда:
а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3). Муниципаль торак инспекторлары федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләргә хокуклы:
1) мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан һәм гражданнардан дәлилләнгән язма гарызнамәләр нигезендә соратып алуга;
2) хезмәт таныклыгын һәм муниципаль торак контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерү

билгеләү турындагы боерыгының (күрсәтмәсенең) күчермәсен күрсәтеп, территориягә һәм анда урнашкан күпфатирлы йортларга, социаль файдаланудагы наем йортларына, күпфатирлы йортлардагы гомуми файдалану урыннарына тоткарлыксыз кереп йөрүгә; күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре ризалыгы белән торак урыннарга кереп йөрүгә һәм аларны өйрәнүгә; тикшеренүләр, сынаулар, тикшерүләр, экспертиза уздыруга, социаль файдаланудагы наем йортларында торак урыннарны наемга бирүчеләрнең мондый йортларда торак урыннарны наемга бирүчеләргә һәм наемга алучыларга, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләрен һәм торак урыннарына наем шартнамәләрен төзүгә һәм үтәүгә карата мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен, Россия Федерациясе Торак кодексының 91[18] статьясындагы 2 өлешендә каралган затларның социаль файдаланудагы наем йортларын муниципаль реестрда исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрне раслый торган документларны тапшыру таләпләрен үтәвен тикшерүгә һәм контрольлек итү буенча башка чаралар үткәрүгә;

3) мәҗбүри таләпләрне бозуларны туктату турында, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең срокларын күрсәтеп, һәм (яисә) кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә зыян китерүне булдырмый калу чаралары, федераль законнарда каралган башка чаралар уздыру турында күрсәтмәләр бирүгә;

4) ачыкланган хокук бозуларны бетерүне контрольдә тоту, аларны кисәтү, гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү ихтималын булдырмый калу чараларын, шулай ук ачыкланган хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту чараларын күрүгә, шул исәптән административ җаваплылык каралган мәҗбүри таләпләрне бозуларга бәйле материалларны административ хокук бозу турында эш кузгату мәсьәләсен хәл итү өчен компетенциясенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органына җибәрүгә; мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле материалларны җинаять билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату мәсьәләләрен хәл итү өчен вәкаләтле органнарга җибәрүгә;

5) Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 6 өлешендә билгеләнгән очракларда судка мөрәҗәгать итүгә;

6) федераль законнарда каралган башка хокукларга.»;

б) 4 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;



3) 7 статьяда:

а) 2 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Идарәче оешманың Россия Федерациясе Торак кодексының 162 статьясындагы 2 өлешендә каралган йөкләмәләрне үтәмәве турында күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре, күпфатирлы йорт советы рәисе, торак милекчеләре ширкәте идарә органнары йә торак кооперативы идарә органнары яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы идарә органнары, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 8 өлешендә күрсәтелгән иҗтимагый берләшмәләр, коммерциясез башка оешмалар мөрәҗәгате нигезендә җирле үзидарә органнары биш көн эчендә идарәче оешма эшчәнлеген планнан тыш тикшерү үткәрә.»;

б) 3 өлештә «мәгълүматны» сүзеннән соң «, шул исәптән торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасын кулланып» сүзләрен өстәргә;

в) 4 өлештә «мәгълүматны» сүзеннән соң «, шул исәптән торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасын кулланып» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 9 апреле
№ 19-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 311. «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 өлешнең 4 пунктындагы икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 өлешенең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән хәлләрне раслау өчен кирәкле документлар, шулай ук әлеге статьяның 3 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары йә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына караган һәм дәүләт, муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнаша торган оешмалар эш итүендә булган документлар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында вәкаләтле орган тарафыннан мөстәкыйль рәвештә соратып алына.».



**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 9 апреле
№ 20-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 312. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:
а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«10 статья. **Ачык акционер җәмгыять акцияләрен, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлешләрен, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын сатканда конкурс шартларын әзерләү һәм раслау тәртибе»;**
б) 1 өлештә:
«өлешләрен» сүзеннән соң «, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни

ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын (алга таба — мәдәни мирас объектлары)» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «мәдәни мирас объектларына,» һәм «реставрация,» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен үткәрү.»;

2) 15 статьяда:

а) 1 өлештә «аларны саклау йөкләмәләрен алган килеш» сүзләрен «мәдәни мирас объектларын тотуга һәм алардан файдалануга таләпләр, мондый объектларны саклап калуга таләпләр, күрсәтелгән объектлардан файдалана алуны тәэмин итүгә таләпләр куелган килеш» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 9 апреле
№ 21-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 313. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Вөҗдан иреге турында һәм дини оешмалар турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 — 2), түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«4. «Экстремистлык эшчәнлегенә каршы көрәш турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль законда йә «Террорчылыкка каршы көрәш турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законда каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшчәнлеген туктату яисә тыю турында законлы көченә кергән карар кабул ителгән иҗтимагый яисә дини берләшмәнең йә башка оешманың элек җитәкчесе булган яисә җитәкче органы составына кергән зат тиешле суд карары законлы көченә кергән көннән алып ун ел дәвамында дини оешма төзи алмый.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 11 апреле
№ 22-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 314. Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:

а) унтугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) егерме җиденче абзацта «хуҗалык һәм башка эшчәнлек субъектлары» сүзләрен «юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар» сүзләренә алмаштырырга;

в) кырыгынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалана алу мөмкинлеге булган иң яхшы технология — продукция (товарлар) җитештерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү технологиясе, ул, куллану өчен техник мөмкинлекләр булганда, фән һәм техниканың заманча казанышларына һәм әйләнә-тирә мохитне саклау максатларына ирешү критерийлары бергәлегенә нигезләнеп билгеләнә;»;

г) кырык өченче абзацта «иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган башка берләшмәләрнең,» сүзләрен «иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган оешмаларның» сүзләренә алмаштырырга;

д) алтмышынчы абзацта «чүпләндерүгә,» сүзен төшереп калдырырга;

е) алтмыш бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«технологик нормативлар — пычраткыч матдәләрне һавага чыгаруның һәм чыгарып ташлауның, физик йогынтыларның технологик күрсәткечләр кулланып билгеләнә торган мөмкин нормативлары;»;



ж) алтмыш алтынчы абзацта «табигатьне саклау нормативлары» сүзләрен «әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге нормативлар» сүзләренә алмаштырырга;

з) алтмыш җиденче абзацта «хуҗалык һәм башка эшчәнлек субъекты» сүзләрен «юридик зат яисә индивидуаль эшкуар» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда:

а) унбишенче абзацта «гамәлдәге» сүзен «мөмкин булган» сүзләренә алмаштырырга;

б) уналтынчы абзацта «иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган башка берләшмәләрнең» сүзләрен «иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган оешмаларның» сүзләренә алмаштырырга;

в) унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт җайга салуының хуҗалык эшчәнлеге һәм (яисә) башка төрле эшчәнлек башкаручы яисә шундый эшчәнлек башкаруны планлаштыручы юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга карата кулланыла торган чараларын билгеләүгә гомуми һәм индивидуаль алымнарның бергәлеген тәэмин итү;»;

г) егерме өченче абзацта «иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган башка берләшмәләрнең» сүзләрен «иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган оешмаларның» сүзләренә алмаштырырга;

д) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әйләнә-тирә мохитне пычратуга китергән яисә китерергә мөмкин хуҗалык эшчәнлеге һәм (яисә) башка төрле эшчәнлекне башкаручы юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны булдырмау һәм (яисә) киметү, әлеге йогынтыдан килгән зыяннарны бетерү чараларын финанслауның мәҗбүрилеге.»;

3) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Әйләнә-тирә мохитне саклау объектлары**

Әйләнә-тирә мохитне пычратудан, ярлыландырудан, деградацияләүдән, бозудан, юкка чыгарудан, хуҗалык эшчәнлегенең һәм (яисә) башка эшчәнлекнең бүтән тискәре йогынтысыннан саклау объектлары табигать мохите компонентларыннан, табигать объектларыннан һәм табигать комплексларыннан гыйбарәт.»;

4) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган һәм региональ дәүләт экология күзәтчелегендә торырга тиешле объектларның дәүләт исәбен алып бару;»;

б) ундүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

5) III кисәкнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III КИСӘК
**ЭКОЛОГИЯ ӨЛКӘСЕНДӘ ГРАЖДАННАРНЫҢ, ИҖТИМАГЫЙ БЕРЛӘШМӘЛӘРНЕҢ ҺӘМ КОММЕРЦИЯГӘ КАРАМАГАН ОЕШМАЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ»;**

6) 10 статьяның 2 өлешендәге икенче абзацта «, фондлар» сүзен төшереп калдырырга;

7) 11 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Экология өлкәсендә иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган оешмаларның хокуклары һәм бурычлары»;**

б) 1 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган оешмалар әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә эшчәнлек алып барырга хокуклы, шул исәптән:»;

в) 2 өлештә «Иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган башка берләшмәләр» сүзләрен «Иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

8) 12 статьяда:

а) 1 өлештә «иҗтимагый берләшмәләргә һәм коммерциягә карамаган башка берләшмәләргә» сүзләрен «иҗтимагый берләшмәләргә һәм коммерциягә карамаган оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Вазыйфаи затлар гражданнарга, шулай ук иҗтимагый берләшмәләргә һәм коммерциягә карамаган оешмаларга экология өлкәсендә законнарда каралган хокукларын гамәлгә ашыруга каршылык тудырган очракта, күрсәтелгән вазыйфаи затлар билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;



9) 23 статьяның 1 өлешендә «хуҗалык һәм башка эшчәнлек субъектлары» сүзләрен «юридик затлар яисә индивидуаль эшкуарлар» сүзләренә алмаштырырга;

10) 28 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мөмкин булган иң яхшы технологияләрнең технологик күрсәткечләре.»;

11) 31 статьяның 1 өлешендә «хуҗалык һәм башка эшчәнлек субъектларының» сүзләрен «юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның» сүзләренә алмаштырырга;

12) 47 статьяда:

а) 1 өлештә «экология өлкәсендәге законнарда билгеләнгән» сүзләрен «әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарда билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә I, II, III категорияләргә кертелгән объектларда хуҗалык эшчәнлеге һәм (яисә) башка эшчәнлек алып бара торган юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар җитештерү экология контроле программасын эшлиләр һәм раслыйлар, билгеләнгән таләпләр нигезендә җитештерү экология контроле уздыралар, мәгълүматны документлаштыралар һәм җитештерү экология контроле уздыру нәтиҗәләре буенча алынган белешмәләрне саклыйлар.»;

13) 49 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«49 статья. **Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны дәүләт исәбенә алу**

1. Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны дәүләт исәбенә алу әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектлар турында дөрес мәгълүмат алу, мөмкин булган иң яхшы технологияләрне куллану өлкәләрен билгеләү, программалы-максатчан планлаштыру ысулларын куллану максатларында, шулай ук дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруны планлаштыру максатларында башкарыла.

2. Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны дәүләт исәбенә алу әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларның дәүләт реестрын алып бару рәвешендә башкарыла, ул әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты

ясый торган объектларның федераль дәүләт реестрыннан һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларның региональ дәүләт реестрларыннан гыйбарәт.»;

14) 60 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

15) 65 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«65 статья. **Әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында башкарыла торган хуҗалык эшчәнлегенә һәм (яисә) башка эшчәнлеккә дәүләт ярдәме**

1. Дәүләт юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында башкарыла торган хуҗалык эшчәнлегенә һәм (яисә) башка эшчәнлеккә ярдәм күрсәтә.

2. Әйләнә-тирә мохитне саклау максатларындагы хуҗалык эшчәнлегенә һәм (яисә) башка эшчәнлеккә дәүләт ярдәме түбәндәге юнәлешләр буенча күрсәтелергә мөмкин:

1) әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауны киметү буенча файдалана алу мөмкинлеге булган иң яхшы технологияләрне кертүгә һәм башка чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтү;

2) әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауны киметү гамәлләренә мәгълүмати ярдәм итүгә булышлык күрсәтү;

3) торгызыла торган энергия чыганакларыннан, икенчел ресурслардан файдалануга, әйләнә-тирә мохитнең пычрануын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча нәтиҗәле башка чараларны гамәлгә ашыруны тикшереп торуның яңа ысулларын эшләүгә Россия Федерациясе законнары нигезендә булышлык күрсәтү.»;

16) 66 статьяның 1 өлешендә «хуҗалык һәм башка эшчәнлек субъектларының» сүзләрен «юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның» сүзләренә алмаштырырга;

17) 83 статьяның 6 өлешендә «техник» сүзен «технологик» сүзенә алмаштырырга, «чыгарып ташлауларның һәм» сүзләреннән соң «(яисә)» сүзен өстәргә;

18) 94 статьяның 2 өлешендә «күмү урыннарын» сүзләрен «урнаштыру объектларын» сүзләренә алмаштырырга;



19) 95 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Су баса торган зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре дәүләт ихтыяҗлары өчен алынган очракта, кишәрлекләрне алу җир законнары һәм граждан законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

20) 98 статьяның 13 өлешендәге 2 пунктында «күмү урыннары» сүзләрен «урнаштыру объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

21) 99 статьяның 2 өлешендә «махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы федераль законнар һәм әлеге Кодекс» сүзләрен «махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы законнар, мәдәни мирас объектлары турындагы законнар һәм әлеге Кодекс» сүзләренә алмаштырырга;

22) 102 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җир ресурсларын һәм туфракны саклауның максатлары җирләрне һәм туфракны пычратуны, ярлыландыруны, деградацияләүне, бозуны, юкка чыгаруны, җиргә һәм туфракка башка төрле тискәре йогынтыны булдырмаудан һәм бетерүдән, шулай ук җирләрдән, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту өчен, рациональ файдалануны тәэмин итүдән гыйбарәт.»;

б) 2 өлештә:

2 пунктта «җитештерү һәм куллану калдыклары белән чүпләнүдән һәм туфрак деградациясе барлыкка килерлек башка тискәре (зарарлы) йогынтылардан» сүзләрен «җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычранудан һәм туфрак деградациясе барлыкка килә торган башка тискәре йогынтылардан» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «һәм чүпләүдән» сүзләрен төшереп калдырырга;

23) 119 статьяның 3 өлешендә «вакытлы» сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 16 маендагы 20-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 17 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 5 (I өлеш);

2) «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пунктының «б» пунктчасын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1; 2014, № 5).

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 11 апреле
№ 23-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 315. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш);



2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның беренче абзацында «Дәүләт аккредитациясе булган» сүзләрен «Төп» сүзенә алмаштырырга;

2) 3 пунктта «дәүләт аккредитациясе булган» сүзләрен «төп» сүзенә алмаштырырга;

3) 4 пунктның беренче абзацында «дәүләт аккредитациясе булган» сүзләрен «төп» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 11 апреле
№ 24-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 316. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының $1.1^{1}$ һәм 8.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012,

№ 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); Ватаным Татарстан, 2015, 7 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.1[1] статьяның 4 пунктында «җирле үзидарә органнарының» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 8.2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8.2 статья. **Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар**

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, 19.4[1] статьясындагы 1 өлешендә, 19.5 статьясындагы 1 өлешендә, 19.7 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне түбәндәгеләр төзи:
1) региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген), шулай ук федераль дәүләт күзәтчелеге өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм белгечләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары җитәкчеләре һәм белгечләре, шулай ук вазыйфаи бурычларына эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкару керә торган башка вазыйфаи затлар;
2) муниципаль районнарда, шәһәр округларында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда – муниципаль районнар, шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре, аларның беренче урынбасарлары, урынбасарлары, муниципаль районнар, шәһәр округлары башкарма комитетларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары, шулай ук вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне башкару керә торган муниципаль районнар, шәһәр округлары башкарма комитетларының башка вазыйфаи затлары;
3) җирлекләрдә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда – җирлекләр башлыклары, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарлары (секретарьлары), шулай ук вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне башкару керә торган җирлекләрнең башкарма комитетларының башка вазыйфаи затлары.».



**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 11 апреле
№ 25-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 317. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясындагы 2 пункты дүртенче абзацының, 61 статьясындагы 3 пунктының, 77 статьясындагы 3 пункты алтынчы абзацының (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш) гамәлдә булуын 2016 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2 статья

2015 елда түбәндәгеләрне билгеләргә:
1) 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасы (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фон-

ды бюджеты җыелма бюджет язмасы) күрсәткечләренә 2016 һәм 2017 еллар күрсәткечләре өлешендә үзгәрешләр кертелми;

2) 2016 һәм 2017 елларга бюджет йөкләмәләре лимитлары Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә) җиткерелми;

3) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчаларын алучы) тарафыннан 2016 һәм (яисә) 2017 елларда түләнергә тиешле йөкләмәләр кабул ителгән шартнамәләр (килешүләр) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучыга (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчаларын алучыга) күрсәтелгән елларга бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелмәүгә бәйле рәвештә аның инициативасы белән өзелми;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы исеменнән 2016 елда товарлар кайтару буенча тиешле йөкләмәләр өчен түләүне күздә тота торган шартнамәләр (килешүләр) төзү рөхсәт ителә;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан арткан чорга Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен барлыкка китерүгә бәйле башка шартнамәләр (килешүләр) төзү рөхсәт ителә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 22 апреле
№ 26-ТРЗ





## 318. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта «(1 майдан алып 1 октябрьгә кадәрге чорда сезонлы (җәйге) кафеларда сыраны һәм сыра эчемлекләрен ваклап сатудан тыш)» сүзләрен өстәргә;

2) 5 пунктта «(ишегалларыннан)» сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 22 апреле
№ 27-ТРЗ

## 319. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 3 өлешендәге «е» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру;»;

2) 9 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктның «в» пунктчасында «көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм яңадан эшкәртү» сүзләрен «каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

3) 18 статьяның 5 өлешендә:

а) 3 пунктта «яңа» сүзен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4) җирлекнең, шәһәр округының коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларына, җирлекнең, шәһәр округының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына, җирлекнең, шәһәр округының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына.»;

4) $19^1$ статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:



«7) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю), транспорт белән ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү объектлары;»;

5) $19^2$ статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю) һәм транспорт белән ташу объектлары;»;

6) $19^3$ статьяның 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю), транспорт белән ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү объектлары;».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең бүтән срогы билгеләнгән нигезләмәләрдән гайре, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1, 2, 4 – 6 пунктлары 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 22 апреле
№ 28-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 320. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); 2015, № 3; Ватаным Татарстан, 2015, 15 апрель) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очраклардан тыш, шушы Кодексның 2.8 статьясында, шулай ук 3.8, 3.11, 3.14, 3.15 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне, вәкаләтләрнең бер өлешен башкаруны тапшыру турында эчке эшләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән



килешүгә нигезләнеп, эчке эшләр органнарының (полициянең) вазыйфаи затлары төзи.»;

2) 14 өлештә «2.6, 2.7, 3.2, 3.6, 5.1, 5.2, шулай ук 2.12, 2.13, 3.3 – 3.5, 3.7» сүзләрен «2.6 – 2.8, 3.6, 3.8, 3.11, 3.14, 3.15, 5.1, 5.2, шулай ук 2.4, 2.5, 2.12 – 2.14, 3.2 – 3.5, 3.7, 3.10 (гражданнарга карата)» сүзләре белән алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 7; 2015, № 3), «2.6, 2.7, 2.12, 2.13, 3.2 – 3.7, 3.16» саннарын «2.4 – 2.8, 2.12 – 2.14, 3.2 – 3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14 – 3.16» сүзләре белән алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 25 апреле
№ 29-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 321. Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Казан шәһәрендәге районнар чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм картографик тасвирлама (әлеге Законга 2 нче кушымта) нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын**
**вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 25 апреле
№ 30-ТРЗ



Казан шәһәрендәге районнар
чикләре карта-схемасы

Казан шәһәрендәге районнар чикләре
турында Татарстан Республикасы
Законына 1 кушымта



«Казан шәһәрендәге
районнар чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

## Казан шәһәрендәге районнар чикләренең картографик тасвирламасы

### Казан шәһәренең Авиатөзелеш районы чигенең картографик тасвирламасы

Авиатөзелеш районы чиге Совет районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Совет, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында Казансу елгасы аша тимер юл күперенең уртасында урнашкан X = 482294,23, Y = 1308262,15 координаталы тоташу ноктасыннан алып Казансу елгасы агымы буенча өскә таба 6650 м, елганы кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 470 м агач-куак массивына кадәр, аннары көнчыгышка таба агач-куак массивы буйлап 400 м Лотфулла Фәттахов урамына кадәр бара, Лотфулла Фәттахов урамының так ягы буйлап шушы урамны «Мәскәү – Уфа» М-7 федераль автомобиль юлы белән тоташтыра торган юлга кадәр, шуннан соң әлеге юлның төньяк-көнбатыш ягы буйлап 310 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары «Мәскәү – Уфа» М-7 федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосадан 40 м көньяк-көнбатышта 480 м төньяк-көнбатышка таба бара, төньяк-көнчыгышка борыла һәм 40 м «Мәскәү – Уфа» М-7 федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосада урнашкан X = 488098,57, Y = 1310573,70 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Авиатөзелеш районының басу аша кишәрлеге чиге Совет районы белән чиктәш җирдә Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 490647,85, Y = 1311947,20 координаталы тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба, Казансу елгасын кисеп үтеп, 11 м Казансу елгасының сулъяк ярында урнашкан X = 490648,99, Y = 1311936,30 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Авиатөзелеш районының басу аша кишәрлеге чиге Казан шәһәре чиге буйлап Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 490647,85, Y = 1311947,20 координаталы тоташу ноктасыннан алып Казансу елгасының сулъяк ярында урнашкан X = 490648,99, Y = 1311936,30 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Авиатөзелеш районы чиге Яңа Савин районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Яңа Савин, Авиатөзелеш һәм Мәскәү



районнары чикләре тоташкан урында Дементьев урамы аркылы үтә торган тимер юл үткәргеченең көнчыгыш терәгендә урнашкан X = 481850,50, Y = 1303360,22 координаталы тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 5020 м Горький тимер юлы өеменең төньяк чиге буйлап Казан шәһәренең Яңа Савин, Авиатөзелеш һәм Совет районнары чикләре тоташкан урында X = 482294,23, Y = 1308262,15 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Авиатөзелеш районы чиге Мәскәү районы белән чиктәш җирдә «Сосновая Роща» шифаханәсе коймасының төньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан X = 488272,47, Y = 1299584,22 координаталы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба буаның төньяк-көнбатыш яры буйлап 320 м уза, аннары көньякка таба 2250 м Гудованцев урамының так ягына кадәр, Гудованцев урамының так ягы буйлап 620 м бара, көнчыгышка таба борыла һәм, шушы урамны кисеп үтеп, 30 м бара, аннары 55 м көньякка таба, шуннан соң 17 м көньяк-көнбатышка таба һәм яңадан көньякка таба Гудованцев урамының автомобильләр йөри торган өлешен әлеге урамның так ягындагы йортлар яны территориясеннән Тэцевская урамына кадәр бүлеп торучы линия буйлап уза, көньяк-көнчыгышка таба Тэцевская урамының так ягы буйлап Теплично-Комбинатская урамына кадәр уза, аннары 810 м көньякка таба һәм 320 м көньяк-көнбатышка таба Горький тимер юлы өеменә кадәр бара, шушы өемнең төньяк чиге буйлап Казан шәһәренең Мәскәү, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында Дементьев урамы аркылы үтә торган тимер юл үткәргеченең көнчыгыш терәгендә урнашкан X = 481850,50, Y = 1303360,22 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Авиатөзелеш районы чиге Казан шәһәре чиге буйлап Казан шәһәренең Мәскәү һәм Авиатөзелеш районнары чикләре тоташкан урында «Сосновая Роща» шифаханәсе коймасының төньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан X = 488272,47, Y = 1299584,22 координаталы тоташу ноктасыннан алып Казан шәһәренең Совет һәм Авиатөзелеш районнары чикләре тоташкан урында «Мәскәү – Уфа» М-7 федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосада урнашкан X = 488098,57, Y = 1310573,70 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

### Казан шәһәренең Вахитов районы чигенең картографик тасвирламасы

Вахитов районы чиге Киров районы белән чиктәш җирдә Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 474214,93, Y = 1299252,93 координаталы тоташу ноктасын-

нан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап, Киров дамбасын кисеп үтеп, 5100 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньяк-көнбатышка таба, Киров дамбасын кисеп үтеп, 1450 м төньяк-көнчыгышка таба Казан шәһәренең Вахитов, Киров һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында Казан Кремленең Воскресенская башнясыннан 150 м төньяк-көнчыгышта Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 477310,68, Y = 1304778,07 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Вахитов районы чиге Яңа Савин районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Вахитов, Яңа Савин һәм Киров районнары чикләре тоташкан урында Казан Кремленең Воскресенская башнясыннан 150 м төньяк-көнчыгышта Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 477310,68, Y = 1304778,07 координаталы тоташу ноктасыннан алып Казансу елгасы агымы буенча 3410 м өскә таба Казан шәһәренең Вахитов, Яңа Савин һәм Совет районнары чикләре тоташкан урында «Миллениум» күперенең уртасындагы төньяк-көнчыгыш терәгеннән 730 м көнчыгышта Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 477614,66, Y = 1307723,10 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Вахитов районы чиге Совет районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Вахитов, Совет һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында «Миллениум» күперенең уртасындагы төньяк-көнчыгыш терәгеннән 730 м көнчыгышта Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 477614,66, Y = 1307723,10 координаталы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 880 м Горький тимер юлының тимер юл күчәренә кадәр, аннары Горький тимер юлының тимер юл күчәре буйлап 870 м көньяк-көнбатышка таба һәм 4730 м көньякка таба Казан шәһәренең Вахитов, Совет һәм Идел буе районнары чикләре тоташкан урында «Ометьево» тимер юл станциясе платформасының көньяк-көнбатыш кырыеннан 25 м көнбатышта урнашкан X = 472975,76, Y = 1308147,27 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Вахитов районы чиге Идел буе районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Вахитов, Идел буе һәм Совет районнары чикләре тоташкан урында «Ометьево» тимер юл станциясе платформасының көньяк-көнбатыш кырыеннан 25 м көнбатышта урнашкан X = 472975,76, Y = 1308147,27 координаталы тоташу ноктасыннан алып Универсиада проспекты буйлап Эсперанто урамына кадәр, Эсперанто урамының җөп ягы буйлап Габдулла Тукай урамына кадәр, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Сара Садыйкова урамына кадәр, Сара Садыйкова урамының җөп ягы буйлап Әхтәмов урамына кадәр, Әхтәмов урамының так



ягы буйлап «Электрон» стадионы территориясенең төньяк-көнчыгыш почмагына кадәр уза, көньяк-көнбатышка таба борыла һәм стадион коймасы буйлап аның төньяк-көнбатыш почмагына кадәр, аннары «Портовая» подстанциясе территориясе коймасы буйлап Горький тимер юлы өеменә кадәр бара, әлеге тимер юл өеменең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба Яңа Татар зиратлы коймасының төньяк-көнчыгыш почмагыннан 90 м төньяк-көнчыгышта урнашкан X = 472785,60, Y = 1305147,92 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза, көнбатышка таба борыла, Яңа Татар зиратының төньяк коймасы буйлап Мехчылар урамына кадәр бара, аннары көньякка таба борыла һәм Мехчылар урамы буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 140 м Куйбышев сусаклагычының яр буе сызыгына кадәр уза, сусаклагыч акваториясе буйлап 5750 м көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 471142,07, Y = 1298766,02 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Вахитов районы чиге Казан шәһәре чиге буйлап Казан шәһәренең Вахитов, һәм Идел буе районнары чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 471142,07, Y = 1298766,02 координаталы тоташу ноктасыннан алып Казан шәһәренең Вахитов һәм Киров районнары чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 474214,93, Y = 1299252,93 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

### Казан шәһәренең Киров районы чигенең картографик тасвирламасы

Киров районы чиге Мәскәү районы белән чиктәш җирдә Ремплер авылының көньяк-көнчыгыш читендә урнашкан X = 484134,89, Y = 1293699,60 координаталы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 4970 м шәһәр урман паркының төньяк чиге буйлап, аннары «Казаноргсинтез» ААҖ гә таба бара торган юлның көньяк-көнбатыш ягы буйлап 2520 м, шуннан соң әлеге юлдан аерылган исемсез юл буйлап 1250 м Горький шоссесына кадәр уза, Горький шоссесының җөп ягы буйлап 100 м бара, төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм исемсез юлның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 770 м Восстание урамына кадәр, Восстание урамының так ягы буйлап төньяк-көнчыгышка таба Окольная урамына кадәр, Окольная урамының җөп ягы буйлап көньякка таба Сабан урамына кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба борыла һәм Сабан урамының җөп ягы буйлап Батыршин урамына кадәр, Батыршин урамының так ягы буйлап Галимҗан Баруди урамына кадәр бара, төньяк-

көнчыгышка таба борыла, Галимҗан Баруди урамының так ягы буйлап Серов урамына кадәр, Серов урамының җөп ягы буйлап көньяк-көнчыгышка таба 2 нче Юго-Западная урамына кадәр, 2 нче Юго-Западная урамының так ягы буйлап Мулланур Вахитов урамына кадәр, Мулланур Вахитов урамының так ягы буйлап төньяк-көнчыгышка таба Декабристлар урамына кадәр бара, көньяк-көнчыгышка таба борыла, Декабристлар урамының так ягы буйлап уза, аны кисеп үтә, төньяк-көнчыгышка таба 85 м Казан шәһәренең Мәскәү, Киров һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында Әфганстанда һәлак булган хәрбиләргә Мәңгелек истәлек һәйкәленнән 110 м төньяк-көнчыгышта урнашкан X = 478358,18, Y = 1304453,48 координаталы тоташу ноктасына кадәр бара.

Киров районы чиге Яңа Савин районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Киров, Яңа Савин һәм Мәскәү районнары чикләре тоташкан урында Әфганстанда һәлак булган хәрбиләргә Мәңгелек истәлек һәйкәленнән 110 м төньяк-көнчыгышта урнашкан X = 478358,18, Y = 1304453,48 координаталы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 290 м Декабристлар урамының җөп ягы буйлап Казансу елгасына кадәр, аннары Казансу елгасы акваториясе буйлап 830 м Казан шәһәренең Яңа Савин, Киров һәм Вахитов районнары чикләре тоташкан урында Казан Кремленең Воскресенская башнясыннан 150 м төньяк-көнчыгышта Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 477310,68, Y = 1304778,07 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Киров районы чиге Вахитов районы белән чиктәш җирдә Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 474214,93, Y = 1299252,93 координаталы тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап, Киров дамбасын кисеп үтеп, 5100 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньяк-көнбатышка таба, Киров дамбасын кисеп үтеп, 1450 м төньяк-көнчыгышка таба Казан шәһәренең Вахитов, Киров һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында Казан Кремленең Воскресенская башнясыннан 150 м төньяк-көнчыгышта Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 477310,68, Y = 1304778,07 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Киров районы чиге Казан шәһәре чиге буйлап Казан шәһәренең Киров һәм Вахитов районнары чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 474214,93, Y = 1299252,93 координаталы тоташу ноктасыннан алып Казан шәһәренең Киров һәм Мәскәү районнары чикләре тоташкан урында Ремплер авылының көньяк-көнчыгыш читендә урнашкан X = 484134,89, Y = 1293699,60 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.



## Казан шәһәренең Мәскәү районы чигенең картографик тасвирламасы

Мәскәү районы чиге Авиатөзелеш районы белән чиктәш җирдә «Сосновая Роща» шифаханәсе коймасының төньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан X = 488272,47, Y = 1299584,22 координаталы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба буаның төньяк-көнбатыш яры буйлап 320 м уза, аннары көньякка таба 2250 м Гудованцев урамының так ягына кадәр, Гудованцев урамының так ягы буйлап 620 м бара, көнчыгышка таба борыла һәм, шушы урамны кисеп үтеп, 30 м бара, аннары 55 м көньякка таба, шуннан соң 17 м көньяк-көнбатышка таба һәм яңадан көньякка таба Гудованцев урамының автомобильләр йөри торган өлешен әлеге урамның так ягындагы йортлар яны территориясеннән Тэцевская урамына кадәр бүлеп торучы линия буйлап уза, көньяк-көнчыгышка таба Тэцевская урамының так ягы буйлап Теплично-Комбинатская урамына кадәр уза, аннары 810 м көньякка таба һәм 320 м көньяк-көнбатышка таба Горький тимер юлы өеменә кадәр бара, шушы өемнең төньяк чиге буйлап Казан шәһәренең Мәскәү, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында Дементьев урамы аркылы үтә торган тимер юл үткәргеченең көнчыгыш терәгендә урнашкан X = 481850,50, Y = 1303360,22 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Мәскәү районы чиге Яңа Савин районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Мәскәү, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында Дементьев урамы аркылы үтүче тимер юл үткәргеченең көнчыгыш терәгендә урнашкан X = 481850,50, Y = 1303360,22 координаталы тоташу ноктасыннан алып Ибраһимов проспектының так ягы буйлап көньяк-көнчыгышка таба Ямашев проспектына кадәр уза, Ямашев проспектының җөп ягы буйлап Короленко урамына кадәр бара, Ямашев проспектын кисеп үтә, Ямашев проспектының так ягы буйлап Бондаренко урамына кадәр уза, көньякка таба борыла һәм Бондаренко урамының так ягы буйлап Сибгат Хәким урамына кадәр бара, көньяк-көнбатышка таба борыла, Сибгат Хәким урамы буйлап Казан шәһәренең Мәскәү, Яңа Савин һәм Киров районнары чикләре тоташкан урында Әфганстанда һәлак булган хәрбиләргә Мәңгелек истәлек һәйкәленнән 110 м төньяк-көнчыгышта урнашкан X = 478358,18, Y = 1304453,48 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Мәскәү районы чиге Киров районы белән чиктәш җирдә Ремплер авылының көньяк-көнчыгыш читендә урнашкан X = 484134,89, Y = 1293699,60 координаталы тоташу нокта-

сыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 4970 м шәһәр урман паркының төньяк чиге буйлап, аннары «Казаноргсинтез» ААЖ гә таба бара торган юлның көньяк-көнбатыш ягы буйлап 2520 м, шуннан соң әлеге юлдан аерылган исемсез юл буйлап 1250 м Горький шоссесына кадәр уза, Горький шоссесының җөп ягы буйлап 100 м бара, төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм исемсез юлның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 770 м Восстание урамына кадәр, Восстание урамының так ягы буйлап төньяк-көнчыгышка таба Окольная урамына кадәр, Окольная урамының җөп ягы буйлап көньякка таба Сабан урамына кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба борыла һәм Сабан урамының җөп ягы буйлап Батыршин урамына кадәр, Батыршин урамының так ягы буйлап Галимҗан Баруди урамына кадәр бара, төньяк-көнчыгышка таба борыла, Галимҗан Баруди урамының так ягы буйлап Серов урамына кадәр, Серов урамының җөп ягы буйлап көньяк-көнчыгышка таба 2 нче Юго-Западная урамына кадәр, 2 нче Юго-Западная урамының так ягы буйлап Мулланур Вахитов урамына кадәр, Мулланур Вахитов урамының так ягы буйлап төньяк-көнчыгышка таба Декабристлар урамына кадәр бара, көньяк-көнчыгышка таба борыла, Декабристлар урамының так ягы буйлап уза, аны кисеп үтә, төньяк-көнчыгышка таба 85 м Казан шәһәренең Мәскәү, Киров һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында Әфганстанда һәлак булган хәрбиләргә Мәңгелек истәлек һәйкәленнән 110 м төньяк-көнчыгышта урнашкан X = 478358,18, Y = 1304453,48 координаталы тоташу ноктасына кадәр бара.

Мәскәү районы чиге Казан шәһәре чиге буйлап Казан шәһәренең Киров һәм Мәскәү районнары чикләре тоташкан урында Ремплер авылының көньяк-көнчыгыш читендә урнашкан X = 484134,89, Y = 1293699,60 координаталы тоташу ноктасыннан алып «Сосновая Роща» шифаханәсе коймасының төньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан X = 488272,47, Y = 1299584,22 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

## Казан шәһәренең Яңа Савин районы чигенең картографик тасвирламасы

Яңа Савин районы чиге Авиатөзелеш районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Яңа Савин, Авиатөзелеш һәм Мәскәү районнары чикләре тоташкан урында Дементьев урамы аркылы үтә торган тимер юл үткәргеченең көнчыгыш терәгендә урнашкан X = 481850,50, Y = 1303360,22 координаталы тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 5020 м Горький тимер юлы өеменең төньяк чиге буйлап Казан шәһәренең Яңа Савин, Авиатөзелеш



һәм Совет районнары чикләре тоташкан урында X = 482294,23, Y = 1308262,15 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Савин районы чиге Совет районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Яңа Савин, Совет һәм Авиатөзелеш районнары чикләре тоташкан урында Казансу елгасы аша үтүче тимер юл күперенең уртасында урнашкан X = 482294,23, Y = 1308262,15 координаталы тоташу ноктасыннан алып Казансу елгасы агымы буенча аска таба Казан шәһәренең Яңа Савин, Совет һәм Вахитов районнары чикләре тоташкан урында 730 м көнчыгышта Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 477614,66, Y = 1307723,10 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Савин районы чиге Вахитов районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Вахитов, Яңа Савин һәм Киров районнары чикләре тоташкан урында Казан Кремленең Воскресенская башнясыннан 150 м төньяк-көнчыгышта Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 477310,68, Y = 1304778,07 координаталы тоташу ноктасыннан алып Казансу елгасы агымы буенча 3410 м өскә таба Казан шәһәренең Вахитов, Яңа Савин һәм Совет районнары чикләре тоташкан урында «Миллениум» күперенең уртасындагы төньяк-көнчыгыш терәгеннән 730 м көнчыгышта Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 477614,66, Y = 1307723,10 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Савин районы чиге Киров районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Киров, Яңа Савин һәм Мәскәү районнары чикләре тоташкан урында Әфганстанда һәлак булган хәрбиләргә Мәңгелек истәлек һәйкәленнән 110 м төньяк-көнчыгышта урнашкан X = 478358,18, Y = 1304453,48 координаталы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 290 м Декабристлар урамының җөп ягы буйлап Казансу елгасына кадәр, аннары Казансу елгасы акваториясе буйлап 830 м Казан шәһәренең Яңа Савин, Киров һәм Вахитов районнары чикләре тоташкан урында Казан Кремленең Воскресенская башнясыннан 150 м төньяк-көнчыгышта Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 477310,68, Y = 1304778,07 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Савин районы чиге Мәскәү районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Мәскәү, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында Дементьев урамы аркылы үтүче тимер юл үткәргеченең көнчыгыш терәгендә урнашкан X = 481850,50, Y = 1303360,22 координаталы тоташу ноктасыннан алып Ибраһимов проспектының так ягы буйлап көньяк-көнчыгышка таба Ямашев проспектына кадәр уза, Ямашев проспектының җөп ягы буйлап Короленко урамына кадәр бара, Ямашев проспектын кисеп үтә, Ямашев проспектының так

ягы буйлап Бондаренко урамына кадәр уза, көньякка таба борыла һәм Бондаренко урамының так ягы буйлап Сибгат Хәким урамына кадәр бара, көньяк-көнбатышка таба борыла, Сибгат Хәким урамы буйлап Казан шәһәренең Мәскәү, Яңа Савин һәм Киров районнары чикләре тоташкан урында Әфганстанда һәлак булган хәрбиләргә Мәңгелек истәлек һәйкәленнән 110 м төньяк-көнчыгышта урнашкан X = 478358,18, Y = 1304453,48 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

## Казан шәһәренең Идел буе районы чигенең картографик тасвирламасы

Идел буе районы чиге Вахитов районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Вахитов, Идел буе һәм Совет районнары чикләре тоташкан урында «Ометьево» тимер юл станциясе платформасының көньяк-көнбатыш кырыеннан 25 м көнбатышта урнашкан X = 472975,76, Y = 1308147,27 координаталы тоташу ноктасыннан алып Универсиада проспекты буйлап Эсперанто урамына кадәр, Эсперанто урамының җөп ягы буйлап Габдулла Тукай урамына кадәр, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Сара Садыйкова урамына кадәр, Сара Садыйкова урамының җөп ягы буйлап Әхтәмов урамына кадәр, Әхтәмов урамының так ягы буйлап «Электрон» стадионы территориясенең төньяк-көнчыгыш почмагына кадәр уза, көньяк-көнбатышка таба борыла һәм стадион коймасы буйлап аның төньяк-көнбатыш почмагына кадәр, аннары «Портовая» подстанциясе территориясе коймасы буйлап Горький тимер юлы өеменә кадәр бара, әлеге тимер юл өеменең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба Яңа Татар зираты коймасының төньяк-көнчыгыш почмагыннан 90 м төньяк-көнчыгышта урнашкан X = 472785,60, Y = 1305147,92 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза, көнбатышка таба борыла, Яңа Татар зиратының төньяк коймасы буйлап Мехчылар урамына кадәр бара, аннары көньякка таба борыла һәм Мехчылар урамы буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 140 м Куйбышев сусаклагычының яр буе сызыгына кадәр уза, сусаклагыч акваториясе буйлап 5750 м көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 471142,07, Y = 1298766,02 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Идел буе районы чиге Совет районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Идел буе, Совет һәм Вахитов районнары чикләре тоташкан урында «Ометьево» тимер юл станциясе платформасының көньяк-көнбатыш кырыеннан 25 м көнбатышта урнашкан X = 472975,76, Y = 1308147,27 координаталы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба Универсиада проспекты буйлап Танк урамына кадәр уза, төньяк-көнчыгышка таба борыла, Танк урамы буйлап Рихард Зорге урамына кадәр, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба йортлар яны территориясенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Рихард Зорге урамындагы 24 нче һәм 13а йортлары буйлап Бертуган Касыймовлар урамына кадәр, Бертуган Касыймовлар урамының так ягы буйлап көнчыгышка таба 1165 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 246 м Җиңү проспектына кадәр бара, Җиңү проспектының так ягы буйлап төньяк-көнчыгышка таба борыла, аны кисеп үтә, Академик Завойский урамының автомобильләр йөри торган юлын шушы урамның җөп ягындагы йортлар яны территориясеннән бүлүче сызык буйлап көнчыгышка таба 7 нче Нокса тыкрыгына кадәр, аннары 7 нче Нокса тыкрыгы буйлап Нокса елгасына кадәр, елга агымы буенча өскә таба Нокса елгасы үзәнендә урнашкан X = 469560,90, Y = 1318401,45 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Идел буе районы чиге Казан шәһәре чиге буйлап Казан шәһәренең Идел буе һәм Совет районнары чикләре тоташкан урында Нокса елгасы үзәнендә урнашкан X = 469560,90, Y = 1318401,45 координаталы тоташу ноктасыннан алып Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 471142,07, Y = 1298766,02 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

## Казан шәһәренең Совет районы чигенең картографик тасвирламасы

Совет районы чиге Идел буе районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Идел буе, Совет һәм Вахитов районнары чикләре тоташкан урында «Ометьево» тимер юл станциясе платформасының көньяк-көнбатыш кырыеннан 25 м көнбатышта урнашкан X = 472975,76, Y = 1308147,27 координаталы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба Универсиада проспекты буйлап Танк урамына кадәр уза, төньяк-көнчыгышка таба борыла, Танк урамы буйлап Рихард Зорге урамына кадәр, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба йортлар яны территориясенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Рихард Зорге урамындагы 24 нче һәм 13а йортлары буйлап Бертуган Касыймовлар урамына кадәр, Бертуган Касыймовлар урамының так ягы буйлап көнчыгышка таба 1165 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 246 м Җиңү проспектына кадәр бара, Җиңү проспектының так ягы буйлап төньяк-көнчыгышка таба борыла, аны кисеп үтә, Академик Завойский урамының автомобильләр йөри торган юлын шушы урамның җөп ягындагы йортлар яны территориясеннән бүлүче сызык буйлап

көнчыгышка таба 7 нче Нокса тыкрыгына кадәр, аннары 7 нче Нокса тыкрыгы буйлап Нокса елгасына кадәр, елга агымы буенча өскә таба Нокса елгасы үзәнендә урнашкан X = 469560,90, Y = 1318401,45 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Совет районы чиге Вахитов районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Вахитов, Совет һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында «Миллениум» күперенең уртасындагы төньяк-көнчыгыш терәгеннән 730 м көнчыгышта Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 477614,66, Y = 1307723,10 координаталы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 880 м Горький тимер юлының тимер юл күчәренә кадәр, аннары Горький тимер юлының тимер юл күчәре буйлап 870 м көньяк-көнбатышка таба һәм 4730 м көньякка таба Казан шәһәренең Вахитов, Совет һәм Идел буе районнары чикләре тоташкан урында «Ометьево» тимер юл станциясе платформасының көньяк-көнбатыш кырыеннан 25 м көнбатышта урнашкан X = 472975,76, Y = 1308147,27 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Совет районы чиге Яңа Савин районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Яңа Савин, Совет һәм Авиатөзелеш районнары чикләре тоташкан урында Казансу елгасы аша үтүче тимер юл күперенең уртасында урнашкан X = 482294,23, Y = 1308262,15 координаталы тоташу ноктасыннан алып Казансу елгасы агымы буенча аска таба Казан шәһәренең Яңа Савин, Совет һәм Вахитов районнары чикләре тоташкан урында 730 м көнчыгышта Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 477614,66, Y = 1307723,10 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Совет районы чиге Авиатөзелеш районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәренең Совет, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында Казансу елгасы аша тимер юл күперенең уртасында урнашкан X = 482294,23, Y = 1308262,15 координаталы тоташу ноктасыннан алып Казансу елгасы агымы буенча өскә таба 6650 м, елганы кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 470 м агач-куак массивына кадәр, аннары көнчыгышка таба агач-куак массивы буйлап 400 м Лотфулла Фәттахов урамына кадәр бара, Лотфулла Фәттахов урамының так ягы буйлап шушы урамны «Мәскәү – Уфа» М-7 федераль автомобиль юлы белән тоташтыра торган юлга кадәр, шуннан соң әлеге юлның төньяк-көнбатыш ягы буйлап 310 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары «Мәскәү – Уфа» М-7 федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосадан 40 м көньяк-көнбатышта 480 м төньяк-көнбатышка таба бара, төньяк-көнчыгышка борыла һәм 40 м «Мәскәү – Уфа» М-7 федераль автомобиль юлына бүлеп



бирелгән полосада урнашкан X = 488098,57, Y = 1310573,70 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Совет районы чиге Авиатөзелеш районының басу аша кишәрлеге белән чиктәш җирдә Казансу елгасы акваториясендә урнашкан X = 490647,85, Y = 1311947,20 координаталы тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба, Казансу елгасын кисеп үтеп, 11 м Казансу елгасының сулъяк ярында урнашкан X = 490648,99, Y = 1311936,30 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

Совет районы чиге Казан шәһәре чиге буйлап Казан шәһәренең Совет һәм Авиатөзелеш районнары чикләре тоташкан урында «Мәскәү – Уфа» М-7 федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосада урнашкан X = 488098,57, Y = 1310573,70 координаталы тоташу ноктасыннан алып Казан шәһәренең Идел буе һәм Совет районнары чикләре тоташкан урында Нокса елгасы үзәнендә урнашкан X = 469560,90, Y = 1318401,45 координаталы тоташу ноктасына кадәр уза.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 322. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының $5^1$ статьясына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $5^1$ статьясындагы 2 пунктының беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013,

№ 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (II өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. «Дуслык» орденына, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медаленә, «Фидакарь хезмәт өчен» Татарстан Республикасы медаленә лаек булган һәм картлык буенча яки тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле хезмәт стажына ия булган, пенсиясе «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән затларга социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

1 өлештә «ордены,» сүзен «орденнары, орден медале,» сүзләренә алмаштырырга;

2 өлештә «ордены статуты» сүзләрен «орденнары статуты» сүзләренә, «медальләре һәм мактаулы исемнәре турындагы нигезләмә» сүзләрен «орден медале, медальләре һәм мактаулы исемнәре турындагы нигезләмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда «орденының,» сүзен «орденнарының, орден медаленең,» сүзләренә алмаштырырга;

3) 4 статьяда «орденына,» сүзен «орденнарына, орден медаленә,» сүзләренә алмаштырырга;

4) 2 бүлекнең исемендә «**ордены**» сүзен «**орденнары, орден медале**» сүзләренә алмаштырырга;

5) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Татарстан Республикасы орденнары, орден медале һәм медальләре**

Татарстан Республикасының түбәндәге орденнары, орден медале һәм медальләре гамәлгә куела:



«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены;

«Дуслык» ордены;

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале;

«Фидакарь хезмәт өчен» медале;

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале;

«Ана даны – Материнская слава» медале;

«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале.»;

6) 8 статьяда:

2 өлештә «аерым казанышлары» сүзләрен «аеруча зур казанышлары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $2^{1}$ өлеш өстәргә:

«$2^{1}$. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнүгә тәкъдим ителгән затлар, кагыйдә буларак, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләнгән булырга тиеш.»;

5 өлештә «Орден планкасын күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр,» сүзләрен «Орден планкасы күкрәкнең сул ягына тагыла,» сүзләренә, «урнаштыралар» сүзен «урнаштырыла» сүзенә алмаштырырга;

7) түбәндәге эчтәлекле $8^{1}$ статья өстәргә:

«$8^{1}$ статья. **«Дуслык» ордены статуты**

1. «Дуслык» ордены белән гражданнар Татарстан Республикасының халыкара абруен, Татарстан Республикасы һәм чит илләр, Россия Федерациясенең башка субъектлары арасында дуслыкны һәм хезмәттәшлекне ныгытудагы аерым казанышлары, Татарстан Республикасының алга китүенә ярдәм итүче икътисадый, сәүдә, фәнни, техник, социаль, мәдәни элемтәләрне һәм сәнәгать куәтен, нәтиҗәле инвестицион, хәйрия һәм иҗтимагый эшчәнлекне үстерүгә зур өлеш керткән өчен бүләкләнәләр.

2. «Дуслык» орденына лаек булган затлар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең Россия Федерациясе, СССР орденнары һәм медальләре, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены булганда, алардан соң урнаштыралар.

3. «Дуслык» орденын көн саен тагып йөрү өчен орден планкасы кулланыла. Орденны орден планкасы белән тагып йөрү рөхсәт ителми.

4. Орден планкасы күкрәкнең сул ягына тагыла, ә бүләкләнүчеләрнең Россия Федерациясе, СССР орденнары һәм медальләре, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены планкалары булганда, алардан соң урнаштырыла.»;

8) түбәндәге эчтәлекле $8^2$ статья өстәргә:

«$8^2$ статья. **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале турында нигезләмә**

1. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән гражданнар Татарстан Республикасының дәүләтчелеген үстерүдәге, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итүдәге, икътисадны, мәдәниятне, фәнне, мәгарифне, сәламәтлек саклауны, сәнгатьне һәм спортны үстерүдәге аерым казанышлары, җәмәгать тәртибен саклаганда, шулай ук гомерләренә куркыныч янау шартларында хәрби, граждани яисә хезмәт бурычын үтәгәндә батырлык һәм кыюлык күрсәткән, актив җәмәгать һәм хәйрия эшчәнлеге өчен бүләкләнәләр.

2. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медаленә лаек булган затлар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең Россия Федерациясе, СССР орденнары һәм медальләре, Татарстан Республикасы орденнары булганда, алардан соң урнаштыралар.

3. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медален көн саен тагып йөрү өчен планка кулланыла. Орден медален планка белән тагып йөрү рөхсәт ителми.

4. Планка күкрәкнең сул ягына тагыла, ә бүләкләнүчеләрнең Россия Федерациясе, СССР орденнары һәм медальләре, Татарстан Республикасы орденнары планкалары булганда, алардан соң урнаштырыла.»;

9) 9 статьяда:

1 өлештә «һәм фәнни» сүзләрен «, фәнни һәм техник» сүзләренә, алмаштырырга, «, актив җәмәгать һәм хәйрия эшчәнлеге өчен» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Фидакарь хезмәт өчен» медаленә лаек булган затлар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең Россия Федерациясе, СССР орденнары һәм медальләре, Татарстан Республикасы орденнары, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале булганда, алардан соң урнаштыралар.»;



10) 10 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медаленә лаек булган затлар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең Россия Федерациясе, СССР орденнары һәм медальләре, Татарстан Республикасы орденнары, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале, «Фидакарь хезмәт өчен» медале булганда, алардан соң урнаштыралар.»;

11) 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 статья. **Татарстан Республикасы мактаулы исемнәренең төрләре**

Татарстан Республикасында түбәндәге мактаулы исемнәр билгеләнә:

1) «Татарстан Республикасының Халык артисты»;
2) «Татарстан Республикасының Халык язучысы»;
3) «Татарстан Республикасының Халык шагыйре»;
4) «Татарстан Республикасының Халык укытучысы»;
5) «Татарстан Республикасының Халык рәссамы»;
6) «Татарстан Республикасының Атказанган агрономы»;
7) «Татарстан Республикасының Атказанган артисты»;
8) «Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы»;
9) «Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы»;
10) «Татарстан Республикасының Атказанган табибы»;
11) «Татарстан Республикасының Атказанган газ тармагы хезмәткәре»;
12) «Татарстан Республикасының Атказанган геологы»;
13) «Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе»;
14) «Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе»;
15) «Татарстан Республикасының Атказанган терлекчесе»;
16) «Татарстан Республикасының Атказанган җиртөзәре»;
17) «Татарстан Республикасының Атказанган зоотехнигы»;
18) «Татарстан Республикасының Атказанган уйлап табучысы»;
19) «Татарстан Республикасының Атказанган урманчысы»;
20) «Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе»;
21) «Татарстан Республикасының Атказанган мелиораторы»;

22) «Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»;

23) «Татарстан Республикасының Атказанган нефтьчесе»;

24) «Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре»;

25) «Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»;

26) «Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»;

27) «Татарстан Республикасының Атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»;

28) «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре»;

29) «Татарстан Республикасының Атказанган җиңел сәнәгать хезмәткәре»;

30) «Татарстан Республикасының Атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре»;

31) «Татарстан Республикасының Атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»;

32) «Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»;

33) «Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»;

34) «Татарстан Республикасының Атказанган яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәре»;

35) «Татарстан Республикасының Атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»;

36) «Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре»;

37) «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре»;

38) «Татарстан Республикасының Атказанган рационализаторы»;

39) «Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»;

40) «Татарстан Республикасының Атказанган коткаручысы»;

41) «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе»;

42) «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы»;

43) «Татарстан Республикасының Атказанган химигы»;

44) «Татарстан Республикасының Атказанган экологы»;

45) «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы»;

46) «Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы»;

47) «Татарстан Республикасының Атказанган юристы».»;



12) 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 статья. **Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре турындагы нигезләмә**

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре түбәндәгеләргә бирелә:

1) «Татарстан Республикасының Халык артисты» — югары осталыкка ия булган, якты сәнгать образлары, спектакльләр, кинофильмнар, телеспектакльләр, телефильмнар, концерт, эстрада, цирк программалары, музыкаль, телевизион һәм радио әсәрләре иҗат иткән, республиканың сәнгати мәдәниятенә зур өлеш керткән һәм җәмәгатьчелектә киң танылган артистларга, режиссерларга, балетмейстерларга, дирижерларга, хормейстерларга, музыкаль башкаручыларга һәм башка сәнгать әһелләренә. «Татарстан Республикасының Атказанган артисты» яисә «Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр бирелгәннән соң, кагыйдә буларак, кимендә 10 ел узгач бирелә (беренче партияләрне башкаручы балет артистларына — кимендә биш ел узгач);

2) «Татарстан Республикасының Халык язучысы» һәм «Татарстан Республикасының Халык шагыйре» — иң күренекле, киң танылган сәнгать әсәрләре иҗат иткән шагыйрьләргә, язучыларга, драматургларга, прозаикларга;

3) «Татарстан Республикасының Халык укытучысы» — белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның мәгарифне үстерүгә зур өлеш керткән һәм җәмәгатьчелектә киң танылган педагогик һәм башка хезмәткәрләренә. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» яисә «Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре» мактаулы исеме бирелгәннән соң, кагыйдә буларак, кимендә биш ел узгач бирелә;

4) «Татарстан Республикасының Халык рәссамы» — рәсем сәнгате, скульптура, графика, монументаль, декоратив-гамәли, театр, кино һәм телевидение сәнгатендә иң күренекле әсәрләр иҗат иткән, республиканың сәнгати мәдәниятенә зур өлеш керткән һәм җәмәгатьчелектә киң танылган рәссамнарга;

5) «Татарстан Республикасының Атказанган агрономы» — белгечлеге буенча кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал агрономнарга, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләргә игенчелекне фәнгә таянып алып бару нигезендә алынган экологик чиста авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең югары икътисадый нәтиҗәлелегенә ирешкән, туфрак уңдырышлылыгын киңрәк яхшырту буенча нәтиҗәле агроалымнар комплексын тәэмин иткән, үсемлекләр селекциясе һәм аларны саклау буенча уңышлы эшләгән, орлыкчылыкны һәм сорт алмаштыру эшен үрнәк бу-

лырлык итеп куйган, табигый терлек азыгы җирләрен нәтиҗәле алып барган һәм файдаланган, квалификацияле белгечләр әзерләгән өчен;

6) «Татарстан Республикасының Атказанган артисты» — сәнгать өлкәсендә, кагыйдә буларак, кимендә 10 ел эшләүче, җәмәгатьчелектә танылган югары сәнгать образлары, спектакльләр, кинофильмнар, телеспектакльләр, телефильмнар, концерт, эстрада, цирк программалары, музыкаль, телевизион һәм радио әсәрләре иҗат иткән югары профессионал артистларга, режиссерларга, балетмейстерларга, дирижерларга, хормейстерларга, музыкаль башкаручыларга һәм башка сәнгать әһелләренә;

7) «Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы» — белгечлеге буенча, кагыйдә буларак, кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал архитекторларга, реставраторларга, шәһәр төзүчеләргә, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләргә шәһәр төзелеше өлкәсендәге, граждан, сәнәгать һәм авыл архитектура комплекслары, биналар һәм корылмалар төзүдәге һәм реконструкцияләүдәге, җәмәгатьчелектә киң танылган тарих һәм мәдәният ядкарьләрен реставрацияләүдәге, архитектура өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшендәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

8) «Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы» — ветеринария өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал ветеринария табибларына, фәнни, педагогик һәм башка хезмәткәрләргә ветеринария өлкәсендәге, эшендә фән һәм техниканың заманча казанышларын кулланып, дәвалау-профилактика ярдәмен оештырудагы, республиканың эпизоотик һәм ветеринария-санитария иминлеген тәэмин итүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

9) «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» — белгечлеге буенча кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал табибларга, табиблык белгечлеге булган фәнни, педагогик һәм башка хезмәткәрләргә халык сәламәтлеген саклаудагы, медицина ярдәменең һәм аннан файдалану мөмкинлегенең сыйфатын яхшыртудагы, эшендә медицина фәненең һәм техникасының заманча казанышларын кулланып, дәвалау-профилактика ярдәмен оештырудагы, диагностикалауның һәм дәвалауның яңа методикаларын кертүдәге һәм кулланылыштагыларын камилләштерүдәге, республика санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итүдәге, медицина фәнен үстерүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

10) «Татарстан Республикасының Атказанган газ тармагы хезмәткәре» — әлеге өлкәдә кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал эшчеләргә, мастерларга, инженер-техник, фәнни,



педагогик һәм башка хезмәткәрләргә Татарстан Республикасы территориясендә газүткәргечләрне төзү, модернизацияләү һәм эксплуатацияләү өлкәсендәге, газны халык ихтыяҗлары һәм сәнәгатьнең төрле тармаклары ихтыяҗлары өчен өзлексез транспортировкалауны тәэмин итүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

11) «Татарстан Республикасының Атказанган геологы» — геология өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, геология, геофизика хезмәтләренең югары профессионал хезмәткәрләренә, фәнни, педагогик хезмәткәрләргә геологик разведка производствосын үстерүдәге, минерал-чимал базасын ныгытудагы, геологик разведка эшләре юнәлешләрен фәнни нигезләүдәге казанышлары өчен, файдалы казылмалар ятмаларын эзләгән, ачкан, разведкалаган һәм сәнәгать үзләштерүенә тапшырган, экологик чиста технологияләрне эшләгән һәм гамәлгә керткән, квалификацияле белгечләр әзерләгән өчен;

12) «Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе» сәнгать өлкәсендә, кагыйдә буларак, кимендә 10 ел эшләүче, мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүгә зур өлеш керткән югары профессионал режиссерларга, балетмейстерларга, дирижерларга, хормейстерларга, композиторларга, шагыйрьләргә, язучыларга, драматургларга, рәссамнарга, архитекторларга, дизайнерларга, сәнгать белгечләренә һәм башка сәнгать әһелләренә иҗади кадрлар тәрбияләүдәге һәм әзерләүдәге, сәнгать өлкәсендә фәнни хезмәтләр иҗат итүдәге зур казанышлары өчен;

13) «Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе» — белгечлеге буенча, кагыйдә буларак, кимендә 10 ел эшләүче, фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсенә ия булган югары квалификацияле фәнни хезмәткәрләргә фән һәм техника, ачыш ясау һәм уйлап табу өлкәсендә аеруча кыйммәтле хезмәтләре өчен яисә республикада күренекле фәнни-гамәли эшчәнлеге өчен, фән һәм техниканың өстенлекле юнәлешләрен эшләүдәге, фәнни мәктәпләр булдырудагы, фәнни кадрлар тәрбияләүдәге һәм әзерләүдәге казанышлары өчен;

14) «Татарстан Республикасының Атказанган терлекчесе» — терлекчелек өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал терлекчеләргә, педагогик һәм башка хезмәткәрләргә югары җитештерү күрсәткечләренә ирешкән өчен, терлекчелекне үстерүдәге, терлекләрнең продуктивлыгын арттырудагы, терлекчелек продукциясенең сыйфатын яхшыртудагы, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

15) «Татарстан Республикасының Атказанган җиртөзәре» — әлеге өлкәдә кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал җиртөзәрләргә, кадастр инженерларына, фәнни, педагогик

һәм башка хезмәткәрләргә җир төзелеше өлкәсендәге, җирдән нәтиҗәле файдалануны планлаштырудагы һәм оештырудагы, дәүләт күчемсез мөлкәт кадастрын булдырудагы һәм алып барудагы, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

16) «Татарстан Республикасының Атказанган зоотехнигы» — белгечлеге буенча кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал зоотехникларга, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләргә зоотехнияне үстерүдәге, терлекчелек үсешен, аның продуктивлыгын арттыруны зоотехник яктан тәэмин итүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

17) «Татарстан Республикасының Атказанган уйлап табучысы» — республика әһәмиятенә ия булган һәм җитештерүгә кертелгән уйлап табуларның республиканың техник алгарышына зур өлеш керткән авторларына;

18) «Татарстан Республикасының Атказанган урманчысы» — урман хуҗалыгы өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, әлеге өлкәнең югары профессионал белгечләренә, фәнни, педагогик һәм башка хезмәткәрләренә, шулай ук табигатьне саклау өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләргә республика урман хуҗалыгын үстерүдәге, урман байлыкларын саклаудагы һәм ишәйтүдәге, үсемлекләр, хайваннар дөньясын саклап калудагы, экологик проблемаларны хәл итүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

19) «Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе» — машина төзелешендә кимендә 10 ел эшләүче, машина төзелешенең югары профессионал эшчеләренә, инженер-техник, фәнни, педагогик һәм башка хезмәткәрләренә машина төзелешен үстерүдәге, җитештерүдәге катлаулы бурычларны оператив һәм югары сыйфатлы үтәүдәге, яңа техника, технологияләр, инновацион производстволар эшләүдәге һәм аларны гамәлгә кертүдәге, продукциянең сыйфатын яхшыртудагы һәм үзкыйммәтен киметүдәге, хезмәт җитештерүчәнлеген, җитештерүнең нәтиҗәлелеген арттырудагы һәм экологик яктан чиста булуын тәэмин итүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

20) «Татарстан Республикасының Атказанган мелиораторы» — мелиорация өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал эшчеләргә, инженер-техник, фәнни, педагогик һәм башка хезмәткәрләргә җитештерү бурычларын үтәүдәге, мелиорация эшләренең сыйфатын яхшыртудагы, мелиорация системаларын эксплуатацияләүдәге, табигать ресурсларын саклаудагы, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;



21) «Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы» — авыл хуҗалыгы өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал механизаторларга, техник-механикларга, педагогик һәм башка хезмәткәрләргә авыл хуҗалыгын механикалаштыру өлкәсендәге, энергияне һәм ресурсларны саклый торган яңа технологияләрне һәм яңа буын техник чараларны гамәлгә кертүдәге, авыл хуҗалыгы техникасыннан файдалануда югары күрсәткечләргә ирешүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

22) «Татарстан Республикасының Атказанган нефтьчесе» — нефть тармагында кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал эшчеләргә, мастерларга, инженер-техник, фәнни, педагогик һәм башка хезмәткәрләргә республиканың нефть сәнәгатен үстерүдәге, фәнни-техник һәм экологик программаларны эшләүдәге һәм гамәлгә ашырудагы, нефть ятмаларын үзләштерүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

23) «Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре» — югары белем бирү өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче һәм кимендә җиде ел педагогик стажга ия, югары белем бирү мәгариф оешмаларының, югары белемгә идарә итү буенча дәүләт органнарының, кагыйдә буларак, фәннәр кандидаты яисә докторы гыйльми дәрәҗәсенә ия булган, югары профессионал педагогик һәм башка хезмәткәрләренә педагогик һәм фәнни эшчәнлектәге, укытуның иң яңа методикаларын һәм методологияләрен эшләүдәге казанышлары, квалификацияле белгечләр әзерләү эшенә зур өлеш кертүләре өчен;

24) «Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре» — торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, торак-коммуналь хуҗалыгының югары профессионал хезмәткәрләренә, педагогик һәм башка хезмәткәрләренә коммуналь хуҗалыкның тотрыклы һәм сыйфатлы эшләвен оештырудагы казанышлары, җитештерүнең нәтиҗәлелеген арттыруда һәм экологик сыйфатын яхшыртуда, яңа техниканы, хезмәт күрсәтүләрнең яңа төрләрен, хезмәтнең алдынгы ысулларын гамәлгә кертүдә, тармакның матди-техник базасын камилләштерүдә һәм алга таба үстерүдә, торак фондының һәм коммуналь хуҗалык объектларының саклануын тәэмин итүдә һәм аларны эксплуатацияләүне, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуда, халыкка югары культуралы хезмәт күрсәтүне тәэмин итүдә, квалификацияле белгечләр әзерләүдә аерым осталык күрсәткәннәре өчен;

25) «Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» — сәламәтлек саклау өлкәсендә кимендә 10

ел эшләүче югары профессионал медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә, сәламәтлек саклау өлкәсендә эшләүче инженер-техник, фәнни, педагогик һәм башка хезмәткәрләргә халык сәламәтлеген саклаудагы, дәвалау-профилактика ярдәме күрсәтүдәге, медицина ярдәменең һәм дарулар белән тәэмин итүнең сыйфатын күтәрүдәге, заманча югары технологияле медицина җиһазы эшләүдәге һәм аны гамәлгә кертүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

26) «Татарстан Республикасының Атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре» – мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, әлеге өлкәнең югары профессионал хезмәткәрләренә, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләренә элемтә чараларын үстерүдәге һәм камилләштерүдәге, шулай ук аларның югары сыйфатлы, өзлексез эшләвен тәэмин итүдәге, инфокоммуникацион инфраструктура эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырудагы, халыкка һәм оешмаларга хезмәт күрсәтүне яхшыртудагы, принципиаль яңа югары нәтиҗәле техниканы һәм технологияне эшләүдәге һәм гамәлгә кертүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

27) «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» – мәдәният өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, мәдәният, кинематография, телевидение, радиотапшырулар, туризм өлкәсенең югары профессионал хезмәткәрләренә, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләренә, шулай ук үзешчән иҗатта катнашучыларга һәм иҗтимагый башлангычларда мәдәниятне һәм сәнгатьне оештыру эшендә катнашучыларга мәдәниятне үстерүдәге һәм популярлаштырудагы, күпмилләтле мәдәни һәм тарихи мирасны, рухи хәзинәләрне һәм гаилә традицияләрен саклап калудагы һәм ишәйтүдәге, китапханә һәм архив эшен үстерүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

28) «Татарстан Республикасының Атказанган җиңел сәнәгать хезмәткәре» – җиңел сәнәгать өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, әлеге өлкәнең югары профессионал хезмәткәрләренә, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләренә җиңел сәнәгатьне үстерүдәге, җитештерүнең нәтиҗәлелеген арттырудагы, фән һәм техника казанышларын гамәлгә кертү, технологияне камилләштерү, җитештерү процессларын механикалаштыру һәм автоматлаштыру исәбенә продукция чыгаруны арттырудагы, аның сыйфатын яхшыртудагы, яңа төр эшләнмәләр ассортиментын киңәйтүдәге казанышлары өчен;

29) «Татарстан Республикасының Атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре» – матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, әлеге өлкәнең югары профессионал хезмәткәрләренә, шулай



ук матбугат хезмәте хезмәткәрләренә һәм фәнни, педагогик хезмәткәрләренә матбугатны, массакүләм мәгълүмат чараларын һәм массакүләм коммуникацияләрне, нәшрият һәм полиграфия эшчәнлеген торгызудагы һәм үстерүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

30) «Татарстан Республикасының Атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре» – азык-төлек сәнәгате һәм кулланучылар кооперациясендә кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал эшчеләргә, инженер-техник, фәнни, педагогик һәм башка хезмәткәрләргә азык-төлек сәнәгатенең ит, сөт, балык, шәраб әзерләү һәм башка тармакларын, кулланучылар кооперациясен үстерүдәге, продукциянең сыйфатын яхшыртудагы һәм ассортиментын киңәйтүдәге, техника һәм технологияне камилләштерүдәге, җитештерү куәтләреннән һәм матди ресурслардан рациональ файдаланудагы, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

31) «Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» – авыл хуҗалыгы өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, агросәнәгать комплексының югары профессионал хезмәткәрләренә, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләренә республика агросәнәгать комплексын үстерүдәге, авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген арттырудагы, шул исәптән авыл хуҗалыгы культураларының уңышын һәм җыемын арттырудагы, туфракның уңдырышлылыгын, терлекнең һәм кош-кортның продуктивлыгын күтәрүдәге, үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен җитештерүне, дәүләткә һәм халыкка сатуны арттырудагы, авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатын яхшыртудагы, экологик сыйфатын тәэмин итүдәге һәм үзкыйммәтен киметүдәге, хезмәт җитештерүчәнлеген арттырудагы, фән һәм техника казанышларын җитештерүгә кертүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

32) «Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» – халыкны социаль яклау өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, әлеге өлкәнең югары профессионал хезмәткәрләренә, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләренә халыкны социаль тәэмин итүнең, аңа социаль ярдәмнең (булышуның), халыкны социаль иминләштерүнең һәм эш белән тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген үстерүдәге һәм арттырудагы, хәйриянең төрле рәвешләрен һәм төрләрен үстерүдәге, халыкны социаль яклауның мөһим юнәлешләре буенча фәнни тикшеренүләр уздырудагы, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

33) «Татарстан Республикасының Атказанган яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәре» – яшьләр сәясәте өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, әлеге өлкәнең югары профессионал хезмәткәрләренә,

педагогик һәм башка хезмәткәрләренә яшьләр проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән программаларны һәм проектларны тормышка ашыруда, яшьләрнең физик һәм рухи үсеше өчен шартлар тудыруда югары казанышларга ирешүләре, яшьләр белән эшләүнең инновацион рәвешләрен эшләүдәге һәм гамәлгә кертүдәге, гражданлык һәм ватанпәрвәрлек тәрбияләүдәге, яшьләр даирәсендә социаль тискәре күренешләрне профилактикалаудагы, яшьләрнең иҗади эшчәнлекләренә ярдәм итүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

34) «Татарстан Республикасының Атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре» — халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, сәүдә, җәмәгать туклануы һәм халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсенең югары профессионал хезмәткәрләренә, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләренә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсен үстерүдәге, эшне оештыру рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерүдәге, оешмаларның матди-техник базасын һәм экологик иминлеген киңәйтүдәге һәм ныгытудагы, халыкка югары культуралы хезмәт күрсәтүне тәэмин итүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

35) «Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» —транспорт өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, әлеге өлкәнең югары профессионал хезмәткәрләренә, фәнни, педагогик һәм башка хезмәткәрләренә заманча транспорт системасын, автомобиль, су, һава, тимер юл һәм башка төр транспортны үстерүдәге, транспорт чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттырудагы, йөртүләрнең үзкыйммәтен киметүдәге, транспорт хезмәтләренең сыйфатын яхшыртудагы, матди һәм ягулык ресурсларын экономияләүдәге, хәрәкәт иминлеген, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итүдәге, пассажирларга хезмәт күрсәтүнең югары культуралылыгын тәэмин итүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

36) «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» — физик культура һәм спорт өлкәсендә, кагыйдә буларак, кимендә 10 ел эшләүче физкультура хәрәкәтен оештыручыларга, спортчыларга, тренерларга, фәнни, педагогик һәм башка хезмәткәрләргә физик культураны һәм спортны үстерүдәге, оештыру-методик, укыту-күнекмә, фәнни-педагогик, тәрбияви, инженер-техник һәм хуҗалык эшчәнлеген үстерүдәге, халыкны физик тәрбияләү системасын, массакүләм спортны һәм югары казанышлар спортын камилләштерүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

37) «Татарстан Республикасының Атказанган рационализаторы» — тәкъдимнәрен гамәлгә кертү җитештерүне камилләштерүгә, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә, продукция сыйфатын, хезмәт шартларын һәм куркынычсызлык техникасын яхшыртуга, фәнни-тикшеренү һәм укыту процессын тәэмин итүгә зур өлеш керткән, озак еллар уңышлы рационализаторлык эшчәнлеге алып баручы рационализаторлык тәкъдимнәре авторларына;



38) «Татарстан Республикасы буенча Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре» — эчке эшләр органнарында календарь буенча исәпләгәндә, кагыйдә буларак, кимендә 10 ел хезмәт итүче, Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр органнарының югары профессионал хезмәткәрләренә хокук тәртибен саклаудагы, җинаятьчелеккә каршы көрәшүдәге, җәмәгать иминлеген тәэмин итүдәге, фәнне үстерүдәге, эчке эшләр органнары кадрларын әзерләүдәге һәм тәрбияләүдәге аерым казанышлары өчен;

39) «Татарстан Республикасының Атказанган коткаручысы» — коткаручылар хезмәтләрендә, кагыйдә буларак, кимендә 10 ел хезмәт стажына ия булган, әлеге хезмәтләрнең югары профессионал хезмәткәрләренә һәлакәтләрне, афәтләрне һәм табигый бәла-казаларны булдырмый калудагы һәм алардан килгән зыянны бетерүдәге, яңа коткару техникасын эшләүдәге һәм үзләштерүдәге, кадрлар тәрбияләүдәге һәм укытудагы казанышлары өчен;

40) «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» — төзелеш өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, төзелеш һәм төзелеш материаллары җитештерү өлкәсенең югары профессионал хезмәткәрләренә, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләренә прогрессив проектларны һәм технологияләрне эшләүдәге һәм гамәлгә кертүдәге, хезмәтне механикалаштырудагы һәм автоматлаштырудагы, югары сыйфатлы, экологик чиста төзелеш материалларының инновацион җитештерүләрен булдырудагы, төзелеш эшләре производствосының, иминлегенең һәм сыйфатының югары нәтиҗәлелегенә ирешүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

41) «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» — белгечлеге буенча кимендә 10 ел эшләүче, мәгариф өлкәсенең югары профессионал укытучыларына, мөгаллимнәренә, тәрбиячеләренә һәм башка хезмәткәрләренә укучыларның тирән белемнәр алуын, аларның иҗади куәтен үстерүне һәм камилләштерүне тәэмин итә торган педагогик һәм тәрбияви эшчәнлектәге, инновацион укыту-методик ярдәмлекләр, программалар, автор методикалары булдырудагы, белем бирү процессын фәнни-методик тәэмин итүдәге, бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларда җиңүчеләрне әзерләүдәге, мәгариф системасын үстерүдәге, педагогик кадрлар әзерләүдәге һәм яңадан әзерләүдәге казанышлары өчен;

42) «Татарстан Республикасының Атказанган химигы» — химия һәм нефть химиясе өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, әлеге өлкәнең югары профессионал эшчеләренә, мастерларына, инженер-техник, фәнни, педагогик һәм башка хезмәткәрләренә химия, нефть химиясе, нефть һәм газ эшкәртү сәнәгатен үстерүдәге казанышлары, катлаулы производство бурычларын оператив һәм югары сыйфатлы үтәүдәге, продукциянең сыйфатын яхшыртудагы һәм үзкыйммәтен киметүдәге, техниканы һәм технологияне камилләштерүдәге, продукциянең яңа төрләрен, югары технологияле химия, нефть химиясе һәм нефть эшкәртү производстволарын булдырудагы һәм үзләштерүдәге, хезмәт җитештерүчәнлеген арттырудагы, җитештерүнең нәтиҗәлелеген һәм экологик сыйфатын тәэмин итүдәге казанышлары, фәнни-техник алгарышка, квалификацияле белгечләр әзерләүгә өлеш кертүләре өчен;

43) «Татарстан Республикасының Атказанган экологы» — әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән нәтиҗәле файдалану өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, әлеге өлкәнең югары профессионал хезмәткәрләренә, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләренә табигать ресурсларын саклап калудагы һәм ишәйтүдәге, аз калдыклы һәм калдыксыз технологияләр эшләүдәге һәм үзләштерүдәге, тузан һәм газ тотып кала торган җайланмалар һәм чистарту корылмалары төзүдәге, республика территориясендә табигый экологик системаларны, табигать ландшафтларын һәм комплексларын, биологик төрлелекне саклап калудагы һәм торгызудагы, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен;

44) «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» — белгечлеге буенча кимендә 10 ел эшләүче, икътисад һәм финанс өлкәсенең югары профессионал икътисадчыларына, бухгалтерларына, башка хезмәткәрләренә республика финанс системасын үстерүдәге, оешманың югары икътисадый күрсәткечләргә ирешүенә, республиканың һәм аның аерым территорияләренең икътисадый үсешенә ярдәм итә торган икътисад һәм финанс эшен, исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны яхшыртудагы һәм камилләштерүдәге, икътисад фәнен үстерүдәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге зур казанышлары өчен;

45) «Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы» — энергетика өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, әлеге өлкәнең югары профессионал белгечләренә, фәнни, педагогик һәм башка хезмәткәрләренә республиканың энергетика комплексын үстерүдәге, яңа типтагы энергетика җиһазларын һәм җайланмаларын булдырудагы, проектлаудагы һәм үзләштерүдәге, энергетика объектларын төзүдә, монтажлауда һәм эксплуатацияләүдә экологик хәлне шактый яхшырта



торган прогрессив технологияләрне гамәлгә кертүдәге казанышлары өчен, фәнни тикшеренүләрдә, энергияне сак тотуда, җитештерүне оештыруда, квалификацияле белгечләр әзерләүдә ирешкән уңышлары өчен;

46) «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» — белгечлеге буенча кимендә 10 ел эшләүче югары профессионал юристларга, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләргә законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы, хокукый дәүләт төзүдәге, хокук фәнен үстерүдәге, закон актларын әзерләүдәге, законнарны пропагандалаудагы, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен.»;

13) 23 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнүдән тыш,» сүзләрен төшереп калдырырга;

14) 26 статьяда:

1 өлештә «орден,» сүзен «орден, орден медале,» сүзләренә алмаштырырга;

2 өлештә «Орденның,» сүзен «Орденның, орден медаленең,» сүзләренә алмаштырырга;

15) 29 статьяның 2 өлешендә «Орден,» сүзен «Орденнар, орден медале,» сүзләренә алмаштырырга;

16) 36 статьяның 1 өлешендә «охшаган орден» сүзләрен «охшаган орденнар, орден медале,» сүзләренә, «орденын» сүзен «орденнарын, орден медален» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казань, Кремль
25 апреля 2015 года
№ 31-ЗРТ

## 323. «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләрне Татарстан Республикасы территориясендә куллану срогын билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2006 елның 30 декабрендәге 271-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 4 өлеше нигезендә әлеге Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләр авыл хуҗалыгы базарларына һәм авыл хуҗалыгы кооператив базарларына карата, халык саны бер миллион кешедән артык булган шәһәрләр территорияләрендә урнашканнарыннан тыш, Татарстан Республикасы территориясендә 2020 елның 1 гыйнварыннан кулланыла дип билгеләргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 25 апреле
№ 32-ТРЗ



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 324. Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

1 статья. **Хокукый җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының (алга таба – тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары) төп бурычларын, эшчәнлеген оештыру тәртибен, функцияләрен билгели. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары җәмәгать тәртибен тәэмин итү бурычларын гамәлгә ашыруда һәм җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләрне хәл итүдә дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына ярдәм күрсәтүне оештыру максатларында дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның, иҗтимагый һәм башка берләшмәләрнең, шулай ук гражданнарның үзара эшчәнлеге рәвеше булып тора.

2 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегенең хокукый нигезе**

Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегенең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары һәм җирле үзидарә органнарының хокукый актлары тәшкил итә.

3 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегенең максатлары һәм бурычлары**

1. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының төп бурычлары түбәндәгеләргә ярдәм күрсәтүдән гыйбарәт:

1) җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итүгә;

2) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауга, аларның җәмәгать урыннарында үз-үзләрен тотуын тикшереп торуны гамәлгә ашыруга, балигъ булмаганнарның яшәү урыны буенча культуралы ялын оештыруга;

3) торак йортлардан, шулай ук йорт янындагы һәм ишегалды территорияләреннән файдалану, аларны карап тоту, эксплуатацияләү тәртибен үтәүгә;

4) торак йортларның һәм торак зоналарында урнашкан башка объектларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә;

5) төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүгә, торак зоналарда төзекләндерү объектларын һәм яшел үсентеләрне саклауга;

6) йорт хайваннарын тоту кагыйдәләрен үтәүгә.

2. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары үзләренә беркетелгән территорияләрдә түбәндәгеләрне башкара:

1) җәмәгать тәртибен ныгыту буенча тәкъдимнәр эшләүне һәм аларны дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләренә тапшыруны;

2) хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү, шул исәптән халыкка мәгълүмат бирү һәм хокук белемнәрен пропагандалау чараларын үткәрүне;

3) халыкка консультатив ярдәм күрсәтүне.

4 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеге принциплары**

Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеге түбәндәге принципларга нигезләнә:

1) законлылык;

2) ихтыярыйлык;

3) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өстенлеге;

4) эчке эшләр органнары (полиция), башка хокук саклау органнары, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен алмаштыруга юл куелмау;

5) хәбәрдарлык һәм тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеге турындагы мәгълүматның һәркем өчен мөмкин булуы;

6) хокукка каршы янаулардан һәркемнең закон белән тыелмаган барлык ысуллар ярдәмендә үз-үзен яклау хокукы;

7) эчке эшләр органнары (полиция), башка хокук саклау органнары, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр белән үзара эшчәнлек;

8) гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозган өчен вазыйфаи затларның һәм гражданнарның җаваплылыгы.



5 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларын оештыру тәртибе һәм аларның составы**

1. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары җирле үзидарә органнары карары белән оештырыла.

2. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктын оештыру турындагы карарда аның исеме, аңа беркетелгән территория, аны урнаштыру өчен бирелә торган урын һәм бүлеп бирелә торган матди-техник чаралар хакында, шулай ук җирле үзидарә органының тәртип саклау буенча җәмәгать пункты эшчәнлеген тәэмин итүче, законнар белән билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи заты (алга таба — вәкаләтле вазыйфаи зат) һәм тәртип саклау буенча җәмәгать пункты эшендә катнашучыларның санлы составы хакында мәгълүматлар булырга тиеш.

3. Тәртип саклау буенча җәмәгать пункты эшендә катнашучыларның санлы составы тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән территориядә яшәүче халык санын, тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән территориядә урнашкан оешмалар, иҗтимагый һәм башка берләшмәләр, шул исәптән халык дружиналары, торак милекчеләре ширкәтләре, торак һәм торак-төзелеш кооперативлары санын исәпкә алып билгеләнә. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктының персональ составы вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан билгеләнә.

4. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшендә катнашучылар составына, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләреннән тыш, гражданнар, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый һәм башка берләшмәләр вәкилләре керә ала.

5. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшендә катнашучылар үз вазыйфаларын түләүсез һәм ирекле нигездә башкара.

6. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларын оештыруның тәкъдим ителә торган критерийлары, шул исәптән тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән территориядә яшәүче халык санына, тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән территориядә урнашкан оешмалар, иҗтимагый һәм башка берләшмәләр санына карап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

6 статья. **Гражданнарның тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегендә катнашуы**

1. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегендә 18 яшькә җиткән, үзләре теләк белдергән һәм үзләренең әхлакый сыйфатлары, сәламәтлеге хәле буенча тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегендә катнашырга сәләтле булган Россия Федерациясе гражданнары катнаша ала.

2. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегендә түбәндәгеләр катнаша алмый:

1) кире алынмаган яисә бетмәгән хөкем ителүе булган затлар;

2) үзләренә карата җинаять эзәрлекләве башкарыла торган затлар;

3) белә торып кылган җинаятьләр өчен элек хөкем ителгән затлар;

4) «Җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (үзләштерүгә) һәм террорчылыкны финанслауга каршы тору турында» 2001 елның 7 августындагы 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә экстремистлык эшчәнлегендә яисә террорчылыкта катнашулары турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегенә кертелгән затлар;

5) үз көченә кергән суд карары белән гамәлләрендә экстремистлык эшчәнлеге билгеләре булуы билгеләнгән затлар;

6) психик авырулардан интегүче, наркомания яисә эчкечелек белән авыручы затлар;

7) үз көченә кергән суд карары белән хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалануга сәләте чикле дип танылган затлар;

8) чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) булган затлар.

7 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары функцияләре**

1. Тәртип саклау буенча җәмәгать пункты:

1) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән территориядә җәмәгать тәртибенең һәм җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләрнең торышын өйрәнә, үзенә беркетелгән территориядә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча тиешле дәүләт органнарына, оешмаларга, иҗтимагый берләшмәләргә тәкъдимнәр әзерли һәм кертә;

2) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына керә торган мәгълүматны анализлый һәм аны вәкаләтле участок полициясе хезмәткәре игътибарына җиткерә, ә кичектереп булмый торган



мәгълүмат алганда, тиешле эчке эшләр органының дежур частенә хәбәр итә;

3) үзенә беркетелгән территориядә җәмәгать тәртибен саклауда эчке эшләр органнарына, хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләргә ярдәм күрсәтә, алар белән хезмәттәшлек итә;

4) үзенә беркетелгән территориядә булган хокук бозуларны кылган затларны законнар нигезендә җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне карау өчен мондый хокук бозулар хакындагы мәгълүматны һәм материалларны дәүләт хакимияте органнарына җибәрә;

5) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән территориядә халык арасында хокук белемнәрен пропагандалауны гамәлгә ашыра;

6) вәкаләтле участок полициясе хезмәткәрләренә, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре хезмәткәрләренә гражданнарны кабул итүдә ярдәм күрсәтә;

7) гражданнарны ирекле нигездә тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегенә җәлеп итә;

8) үзенә беркетелгән территориядә хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү чараларын үткәрүгә ярдәм күрсәтә;

9) җирле үзидарә органнары тарафыннан законнар нигезендә билгеләнә торган башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

2. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшендә катнашучылар үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

1) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәргә;

2) вәкаләтле вазыйфаи затның тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыруга бәйле булган йөкләмәләрен һәм күрсәтмәләрен башкарырга.

3. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшендә катнашучылар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) гражданнардан хокук тәртибен бозуны туктатуны таләп итәргә;

2) хокук бозулар фактларын теркәргә һәм алар турында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларына һәм дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына хәбәр итәргә;

3) эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә һәм дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының башка вазыйфаи затларына хокук бозуларны бетерүдә ярдәм күрсәтергә.

8 статья. **Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары белән үзара эшчәнлеге**

1. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары белән үзара эшчәнлекне түбәндәге юллар белән гамәлгә ашыралар:

1) аларның эшчәнлек тәҗрибәсен өйрәнү һәм гомумиләштерү;

2) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеген регламентлаштыра торган норматив хокукый актлар чыгару;

3) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеге өчен аларга беркетелгән территорияләрдә хокук тәртибе торышы турындагы кирәкле мәгълүмат бирү;

4) тәртип саклау буенча җәмәгать пункты эшчәнлегендә актив катнашучы гражданнарны бүләкләү;

5) хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү чараларын бергәләп үткәрү.

2. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары үз компетенциясе чикләрендә:

1) җәмәгать тәртибен тәэмин итү мәсьәләләре буенча кертелгән тәкъдимнәрне карыйлар;

2) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшендә катнашучылар ачыклаган хокук бозуларны кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча законнар нигезендә чаралар күрәләр;

3) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының эшчәнлекләре турындагы мәсьәләләр буенча кабул ителә торган карарлар хакында аларга хәбәр итәләр.

9 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеген матди һәм финанс ягыннан тәэмин итү**

1. Җирле үзидарә органнары тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеге өчен кирәкле урыннар, техник һәм башка матди чаралар бүлеп бирергә мөмкин.

2. Татарстан Республикасы Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслаштырырга хокуклы.



3. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеген матди һәм финанс ягыннан тәэмин итү шулай ук законнарга каршы килми торган тәртиптә һәм рәвешләрдә оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр акчалары, башка кертемнәр исәбеннән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

10 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегендә актив катнашучы затларны бүләкләү**

Вәкаләтле вазыйфаи зат тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегендә актив катнашучы затларны бүләкләү турында дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмалар җитәкчеләренә үтенечнамә юлларга хокуклы.

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актларны ул үз көченә кергән көненнән алып алты ай вакыт эчендә кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 25 апреле
№ 33-ТРЗ

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 325. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җиденче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җиденче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының $5^1$ статьясына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 101-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

3. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 76-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

4. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

5. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.4 һәм 23.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

6. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.



7. «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 103-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 104-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 89-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

10. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында» 71-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

11. Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2014 елдагы эше турында хисап.

12. «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» 102-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» 93-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 97-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләрне Татарстан Республикасы территориясендә куллану

срогын билгеләү турында» 99-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 92-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 100-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

18. «Татарстан Республикасында Җиңү Байрагы күчермәсен куллану турында» 84-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

19. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе турында.

20. 1990 – 2014 елларда Татарстан Республикасы законнары торышы турында доклад.

21. «Татарстан Республикасы Законнары җыелмасын чыгару буенча республика комиссиясе төзү турында» 2009 елның 5 ноябрендәге 478-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында.

22. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2014 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында доклады.

23. «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык, уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составына үзгәреш кертү турында.

24. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 714043-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларының иҗтимагый палаталары эшчәнлеген тәэмин итүне Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертү өлешендә).

25. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый палаталары (советлары) эшчәнлеген тәэмин итүне җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертү өлешендә



үзгәрешләр кертү хакында» 717570-6 номерлы федераль закон проекты турында.

26. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 17 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 730431-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль районнарның һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне Россия Федерациясе субъекты законы белән яңадан бүлү мөмкинлеген бирү хакында).

27. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 48 статьясына һәм «Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 736559-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектында эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә норматив булмаган муниципаль хокукый актларның гамәлдә булуын туктатып тору турында күрсәтмә җибәрү мөмкинлеге бирү хакында).

28. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 733264-6 номерлы федераль закон проекты турында (депутат эшчәнлегенә бәйле чикләүләр өлешендә).

29. «Физик затлар тарафыннан үз мөлкәте һәм банклардагы счетлары (кертемнәре) турында үзләре теләп декларация бирү хакында» 754388-6 номерлы федераль закон проекты турында.

30. «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 727963-6 номерлы федераль закон проекты турында (автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә дәүләт күзәтчелеге һәм муниципаль контроль тәртибен билгеләү вәкаләтләре хакында).

31. «Россия Федерациясе Торак кодексының 89 статьясына үзгәреш кертү турында» 736488-6 номерлы федераль закон проекты хакында (гражданнарга, торак урыннарыннан чыгарылуга бәйле рәвештә, уңайлыклары булган башка торак урыннар бирү өлешендә).

32. «Ветераннар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур

өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

33. «Транспорт куркынычсызлыгы турында» Федераль законның 1 статьясындагы 11 пунктына үзгәрешләр кертү хакында» 715839-6 номерлы федераль закон проекты турында (кече судноларны транспорт чаралары исемлегеннән төшереп калдыру хакында).

34. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Федераль законның 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 717554-6 номерлы федераль закон проекты хакында (статьяның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү турында).

35. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 719543-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ штрафлар билгеләү һәм исәпләү кагыйдәләрен төгәлләштерү өлешендә).

36. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына дәүләт милке (муниципаль милек) белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 721715-6 номерлы федераль закон проекты турында.

37. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6 бүлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 724074-6 номерлы федераль закон проекты турында (җәмәгать урыннарында хайваннарны файдаланып теләнгән өчен җаваплылык билгеләү хакында).

38. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 733457-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чарасын йөртүченең транспорт чарасына идарә итү хокукы бирүче документлары үзе белән булмаганда транспорт чарасын тоткарлауны төшереп калдыру хакында).

39. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиясез йә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә каралган шартларны һәм (яисә) билгеләнгән тәртиптә расланган техник проектлар таләпләрен бозып җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен җаваплылыкны арттыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 734974-6 номерлы федераль закон проекты турында.

40. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 741119-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чаралары хуҗаларының мәҗбүри граждан җаваплылыгын иминләштерү



автоматлаштырылган системасына белешмәләрне үз вакытында һәм төгәл кертмәгән өчен җаваплылык билгеләү хакында).

41. «Балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклап калу турында» Федераль законның 50 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 738365-6 номерлы федераль закон проекты турында (хуҗалык эшчәнлеге һәм су биологик ресурсларына һәм аларның яшәү тирәлегенә йогынты ясый торган башка эшчәнлек башкаруны җайга салу өлешендә).

42. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль законның 10 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 739287-6 номерлы федераль закон проекты турында (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләреннән тиешенчә файдалану фактын раслый торган документлар исемлеген билгеләү өлешендә).

43. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 737572-6 номерлы федераль закон проекты турында.

44. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 65 статьясына үзгәреш кертү турында» 713728-6 номерлы федераль закон проекты хакында (хезмәт шартнамәсе төзегәндә тапшырыла торган документларның исемлеген пенсия иминләштерүенең иминият таныклыгы исеме өлешендә төгәлләштерү турында).

45. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 51 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Краснодар крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

46. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 737080-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган административ җәзалар исемлеген киңәйтү өлешендә).

47. «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 743295-6 номерлы федераль закон проекты турында (гражданнарның язма мөрәҗәгатенә карата таләпләрне киңәйтү өлешендә).

48. «Россия Федерациясендә адвокатлык эшчәнлеге һәм адвокатура турында» Федераль законның 33 статьясына өстәмә кертү хакында» 749037-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларының адвокатлар

палаталарының квалификация комиссияләрен төзү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

49. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 11$^{2}$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

50. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 14.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 749023-6 номерлы федераль закон проекты турында (ирекле сату законнар нигезендә тыелган яисә чикләнгән товарларны (башка әйберләрне) законсыз саткан өчен җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

51. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 һәм 23.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 735304-6 номерлы федераль закон проекты турында (чит ил агенты функцияләрен башкаручы коммерциягә карамаган оешмаларның эшчәнлек тәртибен бозган өчен административ җаваплылыкка тарту вакыты чыгуны төгәлләштерү өлешендә).

52. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 346.43 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 678692-6 номерлы федераль закон проекты хакында (салым салуның патент системасы кулланыла торган хуҗалык эшчәнлеге төрләре исемлегенә икмәк һәм икмәк-күмәч ризыкларын җитештерүне кертү өлешендә).

53. «Россия Федерациясе Салым кодексына үзгәрешләр кертү турында» 755146-6 номерлы федераль закон проекты хакында (махсус салым режимнарын камилләштерү өлешендә).

54. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем турында».

55. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 523-V ДС



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 326. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп биш елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин суд районы буенча:
9 нчы суд участогына – Сабитова Фәридә Айрат кызын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Идел буе суд районы буенча:
7 нче суд участогына – Касыймов Рөстәм Рәфыйк улын;

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Шәйхразиева Юлия Хәйдәр кызын;

Татарстан Республикасы Питрәч суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Геффель Ольга Федоровнаны;

Татарстан Республикасы Тәтеш суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Зиатдинова Әлфия Әсхәт кызын;

Татарстан Республикасы Ютазы суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Газизов Алмаз Фаяз улын.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп ун елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Алабуга суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Рәхимова Лилия Хамматвәли кызын;

Татарстан Республикасы Түбән Кама суд районы буенча:
7 нче суд участогына – Габидуллин Артур Әсхәт улын;

Татарстан Республикасы Чистай суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Бабкин Игорь Владимировичны.

3. Әлеге карарның 2 пункты нигезендә сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының вәкаләтләре чоры моннан алдагы вәкаләтләре чоры тәмамланган көннән башлана.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 524-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 327. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 5[1] статьясына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 101-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 5[1] статьясына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 101-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 525-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 328. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 5[1] статьясына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (101-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 5[1] статьясына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (101-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручыга җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 526-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 329. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 76-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 76-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 527-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 330. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (76-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (76-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручыга җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 528-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 331. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.



3. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

4. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында күрсәтелгән федераль закон проектын караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вәкиле итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 529-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 332. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.4 һәм 23.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.4 һәм 23.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.4 һәм 23.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

3. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

4. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында күрсәтелгән федераль закон проектын караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вәкиле итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәмmәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 530-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 333. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.



3. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында күрсәтелгән федераль закон проектын караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вәкиле итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 531-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 334. «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 103-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 103-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 532-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 335. «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» Татарстан Республикасы законы хакында (103-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» Татарстан Республикасы законын (103-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручыга җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 533-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 336. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 104-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 104-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.



**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 534-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 337. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (104-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (104-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручыга җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 535-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 338. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 89-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 89-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 536-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 339. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (89-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (89-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручыга җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 537-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 340. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында» 71-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында» 71-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 538-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 341. Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2014 елдагы эше турында хисап хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2014 елдагы эше турында хисапны игътибарга алырга.
2. Татарстан Республикасы Хисап палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасында тышкы финанс контроле системасын үстерү, муниципаль дәрәҗәдә тышкы финанс контроле үткәргәндә булышлык күрсәтү эшен дәвам итәргә;

дәүләт финанс контроле барышында ачыклана торган хокук бозуларны квалификацияләү алымнарын камилләштерү эшен дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы дәүләт программалары чараларын гамәлгә ашыруга тотыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының үтәлешен тикшереп тору эшен дәвам итәргә;

планлаштырыла торган бюджет ассигнованиеләрен чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты проектына экспертиза үткәргәндә анализлауны (бәяләүне) тәэмин итәргә;

бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәләрен үз вакытында үтәүне, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән кредитларны үз вакытында кире кайтаруны тикшереп торырга;

Татарстан Республикасы бюджеты турында һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында законнар нигезләмәләренең законнарга ел дәвамында кертелә торган үзгәрешләргә туры килүен тикшереп торуны гамәлгә ашырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 539-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 342. «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» 102-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» 102-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 540-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 343. «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы законы хакында (102-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы законын (102-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручыга җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 541-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 344. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» 93-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Л.А. Якунин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» 93-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 542-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 345. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» Татарстан Республикасы законы хакында (93-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» Татарстан Республикасы законын (93-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручыга җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 543-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 346. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 97-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.һ. Галиев, Р.Г. Ногманов, Н.Н. Рыбушкин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү



хакында» 97-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 544-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 347. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (97-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (97-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручыга җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 545-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 348. «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләрне Татарстан Республикасы территориясендә куллану срогын билгеләү турында» 99-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләрне Татарстан Республикасы территориясендә куллану срогын билгеләү турында» 99-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 546-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 349. «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләрне Татарстан Республикасы территориясендә куллану срогын билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (99-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләрне Татарстан Республикасы территориясендә куллану срогын билгеләү турында» Татарстан Республикасы законын (99-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручыга җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 547-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 350. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 92-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 92-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 548-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 351. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (92-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (92-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручыга җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 549-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 352. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 100-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 100-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2015 елның 8 маена кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2015 елның 8 июненә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 550-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 353. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесен булдырырга.

2. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе турында нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе тасвирламасын;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесенә таныклык тасвирламасын.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 551-V ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2015 елның 16 апрелендәге
551-V ДС номерлы карары белән
расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
«Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе
турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе (алга таба – мактау билгесе) – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы бүләге, ведомство (парламент) аерымлык тамгасы ул.

2. Мактау билгесе белән Россия Федерациясе гражданнары һәм чит ил гражданнары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, парламентаризмны, граждан җәмгыятен, демократияне, парламентара элемтәләрне үстерүгә һәм законлылыкны ныгытуга аеруча зур өлеш керткән өчен, шулай ук актив иҗтимагый-сәяси эшчәнлекләре, закон чыгару (вәкиллекле) органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен бүләкләнергә мөмкин.

3. Мактау билгесе белән бүләкләү турында тәкъдим белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы депутат берләшмәләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының кимендә 10 кешедән гыйбарәт төркеме, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Прокуроры, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзалары – Татарстан Республикасыннан вәкилләр, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Татарстан Республикасыннан сайланган депутатлары, Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының вәкиллекле органнары мөрәҗәгать итә ала.

4. Мактау билгесе белән бүләкләү турындагы мәсьәләне карау өчен әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән тәкъдим белән чыгучыларның һәркайсы, моңа Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе керми, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе исеменә түбәндәге документларны җибәрә:



1) мактау билгесе белән бүләкләү турында язма үтенечнамә;

2) бүләкләнүгә тәкъдим ителгән затның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, парламентаризмны, граждан җәмгыятен, демократияне, парламентара элемтәләрне үстерүгә һәм законлылыкны ныгытуга шәхсән керткән өлеше турында, актив иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге хакында, закон чыгару (вәкиллекле) органнарында хезмәт итүе турында төгәл мәгълүмат бирелгән, шулай ук бүләкләнүгә тәкъдим ителгән затның тәрҗемәи хәленә кагылышлы һәм хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны үз эченә алган белешмә, ул кушымта итеп бирелгән форма буенча тутырыла.

Мактау билгесе белән бүләкләү турында тәкъдим кертүндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитеты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы депутат берләшмәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы шәһәр округының яисә муниципаль районының вәкиллекле органы шулай ук тиешле карарларын юллыйлар.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, үзенә кергән йә үзендә булган әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә мактау билгесе белән бүләкләнү турындагы мәсьәләне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы каравына кертә.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы мактау билгесе белән бүләкләү турында тапшырылган документларны карый һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары белән рәсмиләштерелә торган тиешле карарга килә.

7. Мактау билгесе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан йә, аның йөкләмәсе буенча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең берәр урынбасары тарафыннан тантаналы шартларда тапшырыла.

8. Бүләкләнә торган затка мактау билгесе белән бергә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан имзалана торган расланган үрнәктәге таныклык һәм бүләкләү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары күчермәсе дә тапшырыла.

9. Мактау билгесе кабат бирелми.

10. Мактау билгесе югалган (бозылган) очракта, мактау билгесенең дубликаты бирелми. Мактау билгесе таныклыгы югалган (бозылган) очракта, таныклыкның дубликатын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты бирә.

11. Дәүләт Советының мактау билгесе күкрәкнең уң ягына тагып йөртелә һәм дәүләт бүләкләренең аскы ягына урнаштырыла.

12. Мактау билгесе белән бүләкләү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарын әзерләү, мактау билгесенең таныклыгын рәсмиләштерү, мактау билгесе белән бүләкләнүчеләрне исәпкә алу һәм теркәү эшен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты башкара.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
«Парламентаризм үсешенә өлеш кerткән өчен»
мактау билгесе турында нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
«Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен»
мактау билгесе белән бүләкләү турында үтенечнамәгә белешмә
